ХӘЕРЛЕ АКЧАЛАР

«Мәгариф» илкүләм проекты мәгарифне ни дәрәҗәдә үзгәртә?

> 2

КАМИЯР БАЙТИМЕРОВ:

«Авылда яшәүчеләрнең нибары 25 проценты гына – эшкә яраклы яшьтә»

> 3

ИМАНЛЫ АВЫЛ

Бишмунчаның хикмәте нидә?

> 6

ТАРИХИ ВАКЫЙГА

«ВТ» хәбәрчеләре «Киләчәк уеннары»нда күргән-күзәткәннәре белән бүлешә

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 28 (29188) | Сишәмбе | 5 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ГЕНӘ БЕЗ БӘХЕТЛЕ

КАЗАНДА «ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ЕЛ ИР-АТЫ: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ» РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕНӘ ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

Бәйрәм алды

Хатын-кыз – баласын иркәләп сөюче әни дә, ирләр белән бертигез хезмәт куеп, тормыш дилбегәсен җигелеп тартучы да, яшәүгә дәрт бирүче нәфис, шул ук вакытта көчле зат та. Казанда ел саен үткәрелә торган «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә тагын бер кат әнә шуны искәрттеләр. Без гаиләдә дә, хезмәттә дә үз урынын тапкан гүзәл затлар белән аралаштык.

«Татар-информ»

«Өченче яшь герое» номинациясе җиңүчесе Азнакайдан Таһирә Әсанова быел 100 яшьлек юбилеен каршылый.

«Нәрсә җитә ана булуга!»

Казаннан Гөлнара Фазлыева – биш бала әнисе. Ул бала тәрбияләүне иң җаваплы эш дип саный:

– Хатын-кыз ул укытучы һәм табиб кына түгел, әни дә. Республикабызда ана роленә зур игътибар бирелүенә бик шатмын. Балалар тәрбияләү, аларны үстерү дә – хезмәт. Бала тәрбияләү – милләт тәрбияләү, дигән сүзләр дә бар бит. Җәмгыятьтә әни роле бәяләп бетергесез, – ди «Хатын-кыз – ана» номинациясе җиңүчеләренең берсе.

Гөлнара ханымның олы улы 15 яшьлек Әсхәт – Россия кадеты, «Парашют белән сикерү» һәм «Снайпер» билгеләре белән бүләкләнгән. Тәҗрибәле әни тәрбия серләре белән уртаклашты.

– Иң мөһиме – дин нигезләре, мәхәббәт һәм үз үрнәгең. Балалар тәрбиясендә иң мөһим өч әйбер шул, – диде ул. – Әле менә озак вакыт өйдә торганнан соң, эшкә чыгарга булдым. Хезмәтне саклау буенча белгеч мин. Гаиләмдәге кебек, эшемдә дә барысын җиренә җиткереп, нәтиҗәле һәм сыйфатлы итеп башкарырга тырышам.

«Эшләмәс идем»

Бүген хатын-кыз хезмәт куймаган бер генә тармак та юк дисәк, ялгыш булмас. Җиңүчеләр рәтендәге һәр хатын-кыз соклану һәм хөрмәт уята. Нинди генә һөнәр ияләре юк алар арасында! Кукмара районыннан «Минем язмышым – минем һөнәрем» номинациясендә җиңү яулаган Алсу Шәмсиева электромонтер булып эшли. Стажы – 23 ел.

– Бәләкәй чактан электр станциясе тирәсендә үскән кыз мин. Әтием гомере буе электрик булды. Мин аның юлыннан китәргә уйладым, – дип сөйләде Алсу ханым. – Эшемнең куркыныч булуын аңлыйм. Электр тогының да, бәхетсезлек очрагының да нәрсә икәнен беләм. Шуңа күрә сак кына, чама белән эшлибез. Дөресен әйткәндә, безнең һөнәрне шулай зурларлар дип уйламаган идем. Минем өчен бу көтелмәгән бүләк булды.

Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсендә хезмәт куючы Миләүшә Котдусова – алтынчы разрядлы слесарь. Заводта 41 ел эшли.

– Бүген – әйтеп бетергесез шатлыклы көнем. Хәтта төштә кебек кенә, – дип, хис-кичерешләре белән уртаклашты Миләүшә ханым. – Эшемне яратмасам, 41 ел эшләмәгән булыр идем. 23 ел токарь станогында эшләдем. 14 нче ел слесарь эшен башкарам. Эшкә килгәндә миңа нибары 17 яшь иде. Гомеремдә бер дә үкенгәнем булмады. Авыр дип тормадым, җитәкчеләрнең йөзенә кызыллык китермәдем. Гомерлек бәхетемне дә бирелә очраттым. Ирем белән заводта таныштык. Хәзер бер цехта эшлибез. Ике кызыбыз бар, өч онык үстерәбез.

«Сездән башка дөнья кояшсыз»

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узган тантаналы чарада җиңүчеләрне Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов котлады.

– Хатын-кыз көн саен, сәгать саен игътибарга, мәхәббәткә һәм рәхмәткә лаек. Гүзәл затларның мондый мөнәсәбәткә лаек булуын ир-атларга искәртү өчен, мөгаен, 8 Март бәйрәме уйлап табылгандыр. Хатын-кызлар – җәмгыятьнең рухи нигезе, – диде ул. – 8 Март – газиз әниләребез бәйрәме. «Әни» сүзеннән бөегрәк исем юктыр. Алар исән чакта, без барыбыз да – бала. Ул яктан мин дә бик бәхетле, әнием – беренче укытучым да әле. Хатын-кыздан башка дөнья кояшсыз булыр иде. Ялгызлар тиң ярларын, ә парлылар күбрәк бала тапсын. Хөрмәтле хатын-кызларыбыз, бәхетле булыгыз, безне дә бәхетле итегез! Илне-көнне сөендереп, бәхет-шатлык өләшеп, бөтен дөньясын көнләштереп, матур итеп яшәгез! Сезнең белән генә без бәхетле.

Фикер

Рәсим БАКСИКОВ, Россия Герое:
– Хатын-кызлар, әниләребез, балаларыбызның әниләре – иң якын кешеләребез. Сезнең өчен яшибез, эшлибез, игътибарыбызны һәм күңел җылыбызны бирергә тырышабыз. Теләсә нинди катлаулы вазгыятьтә ирләр өчен төп таяныч – хатын-кыз. Бөек Ватан сугышын искә алсак, хатын-кызлар ир-атлар белән иңгә-иң сугышкан. Хәзер гүзәл затларны утка кертмәскә тырышабыз. Ватанны саклау – ирләр эше. Хатыннарыбыз һәм әниләр безгә тылдан булышалар. Күбесе маскировка челтәрләре үрә, окоп шәмнәре әзерли, оекбашлар бәйли. Матди яктан да, рухи яктан да булдыра алганча ярдәм итәләр. Моның өчен алар алдында баш иябез һәм чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

Ләйсән САФИНА

Авыл акчасы

Татарстан авылларында 45624 пенсионер (эшләмәүче) авыл хуҗалыгында эшләгән өчен өстәмә ала. Салада кимендә 30 еллык хезмәт стажы туплап, картлык яки инвалидлык буенча иминият пенсиясенә ия булучылар бу. Пенсиягә «авыл» өстәмәсе 2033,72 сум тәшкил итә. Ул пенсиянең төп өлешенең (быел – 8134,88 сум) 25 процентын тәшкил итә. III группа инвалидларның иминият пенсиясенә исә 1016,86 сум өстәлә.

Ә инде пенсионер 80 яшькә җитсә яки I группа инвалид булса, пенсиясенең төп өлеше, авыл хуҗалыгында эшләве-эшләмәвенә карамастан, икеләтә артып, 16269,76 сумга җитәчәк. Өстәмә, законда билгеләнгән төп өлештән исәпләнеп, шул ук 2033,72 сумга күбәя.

Шунысы да бар: шәһәрдә эшләп, пенсиягә чыккач кына авылга күченүчеләргә өстәмә бирелми. Гомер буе авыл җирлегендә эшләп, шуннан соң шәһәргә күченүчеләр дә салага кире әйләнеп кайтса гына өстәмәгә исәп тота ала. Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин аңлатып үткәнчә, эшләмәүче пенсионерларга гына өстәмә түләнелә. Эштән киткәннән соң аны ала башлау өчен гариза язып тапшыру сорала.

Бер тиенсез калганнар

Бер көн эчендә республиканың эчке эшләр органнарына 17 кеше мөрәҗәгать иткән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы хәбәренә караганда, мошенникларга алар барлыгы 22 миллион сум акча күчергән. Асылда акча эшләргә хыялланган, әмма ахыр чиктә хәләл акчасыннан коры калу гына түгел, муеннан бурычка да баткан кешеләр бу.

Мәсәлән, Мөслим бистәсендә бер оешма җитәкчесенә криптовалюта биржасына акча салырга тәкъдим иткәннәр. 47 яшьлек хатын-кыз, озак кына уйлаганнан соң, тәкъдим белән ризалашкан. Әмма саклык акчасы булмау сәбәпле, аңа кредит алырга туры килгән. Шулай итеп, җитәкче ханым, 2515000 сумлык кредит алып, акчаны аферистлар счетына җибәргән.

Яшел Үзәндә исә 53 яшьлек хатын-кыз, акча эшләмәкче булып, кырыгалдарларга 2356000 сум акча күчергән. Акчаны берничә кешенең телефон номерына күчерүне сораулары да анда бернинди шик уятмаган. Бу ханымга да банктан кредит алырга туры килгән.

Ә инде Азнакай районы Тымытык авылында 29 яшьлек туташ маркетплейста акча эшләргә тәкъдим итүчеләргә ышанып «янган». Башта аны һәрбер гамәле өчен акча биреп үсендергәннәр. Зуррак керем алу өчен акча кертергә тәкъдим иткәч, ул 300000 мең сумнан артыграк акча күчергән. Шуннан соң «ярдәмчеләре» юкка чыккан.

Яңа җитәкче

Татарстан буенча эчке эшләр министры вазыйфасына генерал-майор Дамир Сатретдинов билгеләнде. Министрлык хезмәткәрләре яңа җитәкче белән 6 мартта таныштырылыр дип көтелә.

Дамир Сатретдиновка 51 яшь. Әстерханда туып-үскән. Эчке эшләр органнарындагы хезмәтен 1994 елда икътисадый җинаятьләргә каршы көрәш бүлегендә башлап җибәргән. Соңрак төбәкнең Эчке эшләр министрлыгында идарә җитәкчесе булган, министр урынбасары – полиция башлыгы вазыйфасын башкарган. 2020 елда берничә ай дәвамында Хакасия полициясе белән идарә иткән, шул ук елны Россия Эчке эшләр министрлыгының Ханты-Манси автономияле округы – Югра буенча идарәсе башлыгы итеп билгеләнгән.

Моңа кадәр Татарстан буенча эчке эшләр министры булып эшләгән Артем Хохоринның вазыйфасыннан китүе турында узган ел ахырында билгеле булды. Ул министр вазыйфасында 2012 елда эшли башлаган иде.

Салкын яз

Татарстанда 8 Март бәйрәме алдыннан урыны белән –19 градуска кадәр суыта.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 6 мартта аз гына кар көтелә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –7...–2 градус күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә –8...–13 градус тәшкил итәчәк.

Пәнҗешәмбе – 7 мартта Татарстанга төньяктан салкын һава үтеп керәчәк. Шуның нәтиҗәсе буларак, төнге сәгатьләрдә һава температурасы –14...–19 градуска кадәр төшәчәк. Көндез җылырак булачак: –3...–8 градус.

8 һәм 9 мартта республикада урыны белән аз гына кар явачак. Көндез һава температурасы –1...–6 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –7...–15 градус булачак.

Сайлау – 2024

Халык кәефе

Мәгълүм булганча, 15–17 март көннәрендә илдә Президент сайлаячакбыз. Халык сайлау участогына барачакмы? Кемгә тавыш бирәчәк? Белгечләр һәм саннар ни сөйләгәнен тыңладык.

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре телефон аша сораштыру уздырып ачыклаганча, респондентларның **77** проценты дәүләт башлыгын сайлауда катнашачагын белдергән.
Кандидатларга килгәндә, халыкның **79** проценты Владимир Путинны сайлаячагын әйткән. Владислав Даванков, Николай Харитонов кандидатурасын **4** проценты сайлаган, **3** проценты Леонид Слуцкийга тавыш бирер идем, дигән. «Бюллетеньне бозачакмын», – диючеләр дә **3** процент.

Мария ЕФЛОВА, КФУның Социаль фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары, социология фәннәре докторы, социаль-сәяси фәннәр бүлеге җитәкчесе:

– Сораштыру нәтиҗәләренә күз салсаң, Татарстанда яшәүчеләрнең 85 проценты Россия Президентын сайлауга барырга әзер булуын әйтте. 61 проценты тавыш бирүдә катнашачагын әйткән. Шушы 85 процентның 80 проценты Владимир Путин кандидатурасын хуплап тавыш бирергә әзер. Николай Харитоновка – 5, Леонид Слуцкийга – 3, Владислав Даванковка – 2 процент. Тагын 10 проценты әле кем өчен тавыш бирергә дип икеләнә.

Әле сайлауга барырга карар кылмаганнар сайлау көннәренә кадәр фикерен үзгәртер дигән фараз бар. Чөнки сайлауга әти-әниләре, әби-бабалары бара, аларны күрәләр. Инде сайлау участогына килгәч, кем өчен тавыш бирүләрен хәл итәләр. Бездә тавыш бирергә килүчеләр саны һәрвакыт югары булды.

Владимир КУТИЛОВ, политтехнолог, «Теория Дарвина» агентлыгы генераль директоры:

– Сайлау участогына гаилә белән тавыш бирергә бару традициясе бар. Карар кылмаган кешеләр дә, икеләнүчеләр дә сайлау участогына юлны табачак. Ул вакытта инде мәгълүмат бирү кампанияләре дә үз эшен эшләячәк. Республика өчен тавыш бирү көннәре – бәйрәм ул.

Фейк-хәбәрләр тарату өчен, хәзерге вакытта социаль челтәрләр, чатлар файдаланыла. Шуңа күрә тәнкыйди фикерләү һәм мәгълүматны кат-кат тикшерү ысуллары турында онытмасак иде. Фейк-һөҗүмнәр нинди булырга мөмкин? Берничә төп юнәлешне карыйк. Беренчесе: барысы да инде сайланган, сайлауга барып торырга кирәкми. Шул рәвешле сайлауга килүчеләр санын киметүгә ирешмәкчеләр. Икенчесе: фальсификацияләр турында хәбәрләр, сайлау процедурасына һөҗүм. Андый күренешләрне ел саен фаш итәбез. Өченчесе: төрле ысуллар белән ил башлыгының теге яисә бу мәсьәләдәге карарлары халык файдасына түгеллеген күрсәтү.

Кирилл РОДИН, Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәгенең дәүләт хакимияте органнары белән эшләү буенча директоры:

– Алда көтелгән сайлауга килүчеләр проценты ил күләмендә узган кампанияләр күрсәткеченнән югарырак. Моңа күп кенә сәбәпләр йогынты ясый. Әйтик, өч көн тавыш бирү, бюллетеньне читтән торып тутыру, тавыш бирү системасының камилләшүе.

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы

Ландыш ӘБҮДАРОВА, язучы:

Гаилә ул: «Әни, апа миңа уенчыгын бирми...» «Кызым, уенчыкларыңны җый...» «Җаным, эштән кайтышлый ипи, сөт һәм пластырь алып кайт әле, кечкенәсенең бармагына шырпы кадалган, пластырь ябыштырсак кына, еламыйм, ди». «Кредитны түләдеңме?» «Нигә телефоныңны алмыйсың? Йөз тапкыр шалтыраттым бит инде!» Гаилә – менә шундый көндәлек проза ул чынында. Ә шигърияте – менә шушы олы хезмәтне ярату аша кабул итүдә.

РОССИЯДӘ – ОНЛАЙН СӘҮДӘ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең онлайн кибетләрдән нәрсә сатып алулары турында белешкән. Халыкның 71 процентының маркетплейслардан нәрсә дә булса сатып алганы бар икән.

47% >> кием-салым һәм аяк киеме
23% >> матурлык һәм сәламәтлек кирәк-яраклары
20% >> көнкүреш техникасы
19% >> балалар товарлары
15% >> азык-төлек
15% >> хобби өчен кирәк-яраклар
12% >> төзелеш һәм ремонт кирәк-яраклары
2% >> зәркән эшләнмәләр

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БУРЫЧЛАР ҮСӘ, БӨЛГЕНЛЕК АРТА, КЕШЕЛӘР КИМИ

Кешелек җәмгыяте проблемаларның моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә үсеше белән очрашуларын дәвам итә. АКШның дәүләт әҗәте йөз көнгә бер триллион долларлык темп белән үсә башлады. Американың барлык эчке тулай продукты 20 триллион доллардан аз гына артык булуын искә алганда, бу – түләп бетерә алмаслык зур сан. Бурычның инде 34 триллион доллардан ашып китүен искә алганда бигрәк тә.

Англиянең дәүләт әҗәте Икенче бөтендөнья сугышыннан соң иң зур темплар белән үсә. Гыйнвар аенда гына Лондон төбәкләргә 600 миллион фунт стерлинг күләмендә ярдәм иткән иде. Хәзер тагын 19 төбәккә 2,5 миллиард фунт стерлинг күләмендә дәүләт ярдәме озатырга мәҗбүр, чөнки үзәктән акча яумаса, банкротлык парады башланачак. Сайлау алдыннан бөлгенлек игълан итү сайлануны оттыруга тиң. Болай да илдә сәяси партияләргә ышаныч 12 процентка гына калган. Чираттан тыш сайлауда парламентка сул карашлы депутат Джордж Гэллоуэй килде. Ул Фәләстыйнны яклый, ә ил Премьеры һәм барлык рәсми җитәкчелеге Израиль яклы. Әмма ил халыкның 19 проценты гына Израильгә мәхәббәтен белдерә.

Быелның февралендә Швециядә банкротлар саны үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 62 процентка үскән. Бөлгенлек күрсәткечләре 19 ай рәттән үсә. Белгечләр, швед бизнесы давыл уртасында, дип белдерә.

Кытай күчемсез милек базарында кризис көчәя. Быелның ике аенда торак сату үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 51,6 процентка кимегән. 2021 ел янәшәсенә куеп карасаң, күчемсез милек сәүдәсе 77 процентка түбәнәйгән. Компартиянең төзелеш тармагын дәүләт акчасы белән коендыруы, күрәсез, булышмый.

Дөньяның алга киткән илләре демографик кризис упкынына төшүнең антирекордлы күрсәткечләренә юлыга. Япониярда – тууның яңа антирекорды. Үткән ел бары тик 758 мең бала дөньяга килгән. Моннан илле ел элек япон хатын-кызлары 3 тапкыр күбрәк бала тапканнар. Илдә туу һәм никахлар саны бер елга 5 процентлык темплар белән кими. Премьер Фумио Кисида демографияне «ил очрашкан кризисларның иң зуры» дип белдерде.

Көньяк Корея кризисы японнарныкына караганда да көчлерәк. 2023 елда анда 230 меңнән азрак бала туган. Бу үткән елдагыга караганда 8 процентка ким. 2017 елда илдә 400 меңләп бала туган, 2020 дә – 300 мең генә. Бала табу яшендәге хатын-кызларга уртача 0,65 бала гына туры килә. Шуңа охшаган кризис Кытайда да бара. Кеше саны кимүнең бер мөшкел ягы бар: кредитны кемгә бирәсең, ипотеканы кем ала?

Россиядә

АРКАДА – ТӨРЕК ҺӘМ КЫТАЙ ПЫЧАГЫ?

Россиядә дә икътисадый проблемаларның яңа йомгагы төенләнеп килә. Үзәк банк илне Кытай һәм Көнбатыш сценариеннан сакларга тырыша: банклар сорап килгән һәркемгә ипотека кредиты өләшүдән туктадылар. Гаризаларның 60 проценты гына канәгатьләндерелә, диләр. Әмма ил өчен санкцияләр яңа кыенлыклар тудыра. Көнбатыш тыюларның яңа пакетларын эшләү белән генә чикләнеп калмый, элек кертелгән чикләүләрнең үтәлешен дә кайгырта башлады. Россия белән элемтәләрен туктатмаган финанс оешмаларына Вашингтон һәм Брюссель икенчел санкцияләр белән яный. Килеп туган вазгыятьтә үзләренә дивидендлар саву белән шөгыльләнүче дус илләр – Кытай, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре американнар таләпләрен үтәргә мәҗбүрләр. Бу илләрнең банклары соңгы айларда Россия белән исәп-хисап ясауны туктата башлады. Сатылган чималга акча алу кыенлашты, булган акчага ул илләрдән товар кайтарту да катлауланды.

Февраль аенда Төркиядән Россиягә товар китерү 33 процентка кимегән. Үткән ел 1 миллиард долларлык товар кайтартылган булса, быел 670 миллион долларлык кына. Беренче ике ай күрсәткече 1,29 миллиард доллар тәшкил итә. Бер ел элек ул сан 2 миллиард доллар булган. Россиядән Төркиягә чимал сату да февральдә 36,65 процентка кимегән. Кайбер товарлар белән сәүдә бөтенләй туктаган. Бу бигрәк тә машина төзелеше продукциясенә карый. Помидорны төрекләр безгә күпме теләсә, шуның кадәр сатачак, ә менә технологик продукция бирү туктатыла дигән сүз бу.

Кытай белән дә вазгыять шундый ук. Алар – төреккә караганда да мөһимрәк партнерлар. Пекин җилкәсен куймаса, безгә бик кыенга туры киләчәк. Моңарчы Россия компанияләре өчен Гонконг иң популяр урын иде. Параллель импорт нигездә шуның аша барды. Әмма февраль ахырында Гонконгка турыдан-туры акча күчереп булмый башлады. Моңарчы санкция исемлегендәге товарларны да шуның аша китерү җиңел иде. Шул сәбәпле йөзләгән россияле бизнесмен үз компанияләрен Гонконгта теркәделәр. Хәзер алар хисабына акча күчереп булмый. Элек Гонконг банклары сумнарны да бик җиңел кабул итсә, хәзер юаньне дә үткәреп булмый.

Кытайның дәүләт банклары да хезмәттәшлекне кире кага. Сәүдә тукталды дигән сүз түгел бу, ләкин әйләнеч юллар сайларга туры килә. Бу импорт товарларның кыйммәтләнүенә китерәчәк. Әлегә бәя 10 процент тирәсе артыр, диләр.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ХӘЕРЛЕ ЭШ

Ишле гаиләләргә – җылы өй, авыруларга – сыйфатлы ярдәм, ә спорт сөючеләргә – яңа үзәк. Түбән Камадан соңгы яңалыклар бу. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов районга эш сәфәренә барды.

tatarstan.ru

Районда Рөстәм Миңнеханов күпбалалы гаиләләр яши торган Борок авылында булды. Биредә 410 җир кишәрлегенә газүткәргечне файдаланууга тапшырдылар. Тантаналы чарада Татарстан Рәисе дә катнашты:

> Барыгызны да әлеге вакыйга белән котлыйм. Мондый программа өчен Россия Президенты Владимир Путинга, шулай ук, дәүләт башлыгы куйган бурычларны лаеклы дәрәҗәдә хәл итүләре өчен, «Газпром» системасына зур рәхмәт.

Газлаштырып бетерү программасы кысасында зәңгәр ягулыкны шәхси хуҗалыкларга кадәр китергәннәр. Яңа газүткәргечнең озынлыгы – 19 чакрым.

Түбән Кама районы һәм шәһәре башлыгы Рамил Муллин әйтүенчә, яңа микрорайон тиз үсә: биредә газүткәргеч, электр энергиясе, элемтә чыбыклары бар, юл салалар. Рөстәм Миңнеханов халык белән дә аралашты. «Балаларыгызга сәлам әйтегез. Сезнең өчен матур һәм уңайлы авыл төзибез. Шәһәр якын урнашкан. Авылның табигате дә курорттагы кебек», – диде Татарстан Рәисе. Борокта яшәүчеләр бу сүзләр белән килеште.

Эш барышында Рөстәм Миңнеханов Түбән Кама үзәк район күпьюнәлешле хастаханәсенең икенче дәвалау корпусын капиталь төзекләндерү нәтиҗәләрен дә карады. Әлеге бинаны 1990 елда салган булганнар. Ремонттан соң ул тулысынча үзгәргән. Бинада барлык инженер челтәрләрен алыштырганнар, яңа лиф та урнаштырганнар. Пациентлар өчен душы булган яңа бүлмәләр бар. Шулай ук табибларга да барлык шартлар тудырылган. Яңартылган дәвалау корпусы Түбән Кама агломерациясе пациентларына сыйфатлы медицина ярдәм күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итәчәк.

Түбән Камада «СИБУР Арена НК» күпфункцияле спорт үзәге дә ачылды. Тантаналы чарада Рөстәм Миңнеханов катнашты. Яңа бина искергән «Дуслык» спорт комплексы базасында төзелгән. Биредә универсаль спорт залы булган яңа корпус сафка баскан, стадион төзекләндерелгән. Тиздән ачык һавадагы спорт мәйданчыкларында да шөгыльләнеп булачак.

Татарстан Рәисе билгеләп үткәнчә, «СИБУР» Татарстанда сәнәгать проектларын гына уңышлы тормышка ашырып калмыйча, республика үсешенә дә зур өлеш кертә.

– Бу матур бина өчен «СИБУР» җитәкчелегенә рәхмәт. Әлеге үзәккә ихтыяҗ зур булачак, чөнки Түбән Кама халкы спортны бик ярата. Монда булачак чемпионнар тәрбияләнәчәк дип ышанам. Шәһәрдә күп кенә техникумнар, көллиятләр, югары уку йортлары да урнашкан. Шуңа күрә студентларыбызның бер спорт комплексында спортның төрле юнәлешләре белән шөгыльләнә алуы мөһим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

«СИБУР» генераль директоры, идарә рәисе Михаил Карисалов әйтүенчә, бу – XXI гасыр корылмасы. «Ул заманча һәм уңайлы. Бина буш урында төзелде диярлек. Бүгеннән биредә белгечләр һәм тренерлар командасы эшли башлаячак. Үзәктә сәламәт яшәү рәвешен яратучылар өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган», – диде ул.

Яңа күпфункцияле спорт үзәгендә елына 432 меңгә кадәр кеше шөгыльләнә алачак, дип фаразлана.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин күпьеллык уңышлы хезмәте өчен 1980–1990 нчы елларда ТАССР Югары Советы Президиумы Секретаре булып эшләгән хезмәт ветераны Дания Салих кызы Дәүләтшинага «Дуслык» орденын тапшырды. Парламент җитәкчесе аны 90 яшьлек юбилее белән дә котлады. Дәүләт бүләген тапшырганда, Фәрит Мөхәммәтшин Дания Дәүләтшинага парламентаризм һәм Татарстан үсешенә керткән зур өлеше өчен рәхмәт әйтте һәм нык сәламәтлек теләде.
Дания Дәүләтшинаның хезмәт юлы Татарстан белән тыгыз бәйләнгән. Ул Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлаганнан соң, хезмәт юлын 1955 елда Алексеевск районының Урта Тигәнәле урта мәктәбендә башлый. Биредә биология һәм география укыта. Соңрак ВЛКСМ Алексеевск районы комитетының беренче секретаре итеп сайлана. Дания Салих кызы 14 елдан артык Лаеш районында, башта район депутатлары Советы башкарма комитеты рәисе, соңрак райкомның беренче секретаре булып эшли. Ул җитәкчелек иткән елларда район үсешенә кагылышлы мөһим мәсьәләләр хәл ителә. Дания Дәүләтшина ТАССР Югары Советына дүрт чакырылышында депутат итеп сайлана. 1980 елда ТАССР Югары Советы Президиумы секретаре була. Бу чорда ул күп кенә социаль әһәмияттәге законнарны эшләүче һәм башлап җибәрүче була.

Белем

АКЧА ҖИМЕШЕ

«МӘГАРИФ» ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЫ БЕЛЕМ СИСТЕМАСЫН НИЧЕК ҮЗГӘРТӘ?

11 мәктәп һәм 10 бакча. «Мәгариф» илкүләм проекты ярдәмендә быел республикада әнә шуның кадәр мәгариф оешмасы төзеләчәк. Алар арасында Казан гына түгел, Биектау, Лаеш, Питрәч районнары да бар. Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин хәбәр итте. Чыгымнар һәм өметләр турында – безнең язмада.

Хәзерге вакытта «Заманча мәктәп», «Һәр баланың уңышы», «Цифрлы мәгариф мохите», «Социаль активлык», «Россия гражданинына патриотик тәрбия бирү» кебек проектлар тормышка ашырыла. Илсур Һадиуллин белдергәнчә, мәгарифне үстерү өчен бигрәк тә инфраструктурага бәйле проектларның файдасы зур. Әйтик, 2019–2023 елларда республикада 46 мәктәп төзелгән. Бу – 40 мең укучыга урыннар дигән сүз. Соңгы биш ел эчендә 82 бакча ачылган. Шуның нәтиҗәсендә 16,5 мең бәләкәчкә өстәмә урыннар булдырылган.

– Яңа мәктәпләр бигрәк тә зур шәһәрләрдә икенче сменада белем алучы укучыларның санын киметергә булышты, – диде министр.

Журналистлар мәктәпкә кабул иткән чорда урыннар җитмәгән районнар турында да кызыксынды. Министр әйтүенчә, нәкъ шул балалар саны күп булган иң кирәкле пунктлар күздә тотылган да инде. Әйтик, Питрәч районының Көек авылында 600 урынга исәпләнгән янкорма төзеләчәк. Казанның «14 нче», «Яңа Горки» микрорайоннарында, «Весна» торак комплексында, Чаллы шәһәре, Биектау, Лаеш районнарында да пәйда булачак алар.

Авыл мәктәпләре дә ярдәмнән коры калмый. Хәзерге вакытта барлыгы 436 «Үсеш ноктасы» үзәге эшли. Проект ярдәмендә уку кабинетлары заманча итеп җиһазландырыла. Ел ахырына кадәр тагын 72 авыл мәктәбендә физика, химия, биология фәннәреннән укыту базасы ныгыячак. Андагы шартлар укучыларны төрле бәйгеләргә, имтиханнарга әзерләүдә зур ярдәм булып тора. Әйтик, узган ел «Үсеш ноктасы» базасында шөгыльләнгән 15 укучы БДИдан 100 балл җыйган. Алар арасында химия һәм биология сынауларыннан 200 балл туплаган Мөслим кызы Лиана Исмәгыйлева да бар.

Бүген Лиана Казан дәүләт медицина университетында укый.

– Әлеге проектның файдасы күп булды. Химия кабинетына материаллар күп кайтты. Тәҗрибәләрне үзебез үткәреп карый алдык, – ди Лиана.

Илсур Һадиуллин фикеренчә, «Үсеш ноктасы» проекты шәһәр мәктәпләрендә дә булырга тиеш. Ни өчен дигәндә, сыйныфта 40ар бала утыра. Аларга да лаборатор эшләрне, тәҗрибәләрне үз куллары белән үткәреп карау кирәк.

«Мәгариф» илкүләм проекты авыру балаларга шартлар тудыруны да күздә тота. Бу җәһәттән мәктәпләр махсус заманча җиһазлар, психолог, дефектологлар белән тәэмин ителгән.

Сәләтле балалар да игътибардан читтә түгел. Татарстан Рәисе ярдәме белән илкүләм олимпиадаларның йомгаклау этабында җиңүчеләр 200 мең сум акча алса, призерларга бу сумма – 100 мең. «Акыллы баш»ларны бәйгегә әзерләүчеләргә дә әҗере бар. Аларга һәр җиңүче һәм призер өчен 86 мең сум акча бирелә. Узган елдан халыкара олимпиадаларда медаль алучы укучыларга да, өлешен керткән педагогларга да түләү арткан.

Патриотик тәрбиягә кагылышлы проект исә меңгә якын мәктәптә директорларның тәрбия эшләре буенча киңәшчеләрен билгеләү мөмкинлеген биргән. Ел ахырына кадәр барлык мәктәпләр дә Россия һәм Татарстанның дәүләт символлары белән тәэмин ителәчәк.

Кадрлар кытлыгын күпмедер дәрәҗәдә киметү өчен «Авыл укытучысы» программасы эшли. 2020 елда башланган проект авыл мәктәпләренә 51 укытучыны кайтарырга булышты.

«Кадрлар» проекты исә белгечләр кытлыгын бетерүне күздә тота. 2028 елга кадәр миллионга якын эшче белгечне әзерләргә туры киләчәк.

– Кадрлар буенча проблемалар җитәрлек. Хәзерге вакытта математика, физика, рус теле укытучылары җитми. Элек без укыганда, I курстан соң мәктәпкә практикага бара идек, хәзер алай түгел. Яшьләрне мәктәпләргә җибәрергә һәм шунда калдыру өчен барысын да эшләргә кирәк. Яшәргә урын, яхшы хезмәт хакы булсын. Кызганыч, боларны күздә тоткан программа юк. Без 320 педагогик класс ачтык. Анда укытучы булырга теләгән 6,5 мең бала укый. Быел 1500е мәктәпне тәмамлый. Шуларның 80 проценты укытырга кайтса, өмет уяныр иде, – ди министр.

Президент Владимир Путин Федераль Җыенга Юлламасында тагын биш илкүләм проект тормышка ашырылачагын әйтте. Аларның барысы да бакча, мәктәп, көллият һәм вузлардагы шартларны яхшыртуны күздә тота. Болар – капиталь ремонт, яңа тулай тораклар төзү, автобуслар белән тәэмин итү, укытучыларның дәрәҗәсен күтәрүгә бәйле чаралар. Димәк, мөмкинлекләр тагын да артачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

28,5 миллиард сум. «Мәгариф» илкүләм проектына 2019–2024 елларда республика һәм федераль бюджеттан шуның кадәр акча бүлеп бирелгән.

КАМИЯР БАЙТИМЕРОВ:

«ФЕРМЕР ЯРЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ»

Гамьле әңгәмә

Бүген Казанда Татарстан фермерларының XXIV съезды узачак. Фермерлар белән авылның киләчәге ничек бәйләнгән? Алар табышка эшлиме? Болар турында без Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе җитәкчесе Камияр БАЙТИМЕРОВ белән сөйләштек.

:: Камияр Мөҗәһитович, узган ел фермерлар башта ашлыкларын сата алмадылар, аннан соң корылык, ашлыкка һәм сөткә түбән хак белән сыналдылар. Болар барысы да фермерларга нинди йогынты ясады?

– Шәхси хуҗалыклар һәм фермерлар өчен узган ел чыннан да авыр булды. Андый еллар сирәк була. Июньнең уртасына кадәр суыклар белән сыналдык, чыккан игеннәрне дә кырау сукты. Шуңа күрә телгән кадәр уңыш җыеп алып булмады. 2022 елда без 1 млн 231 мең тонна ашлык җыеп алган идек. Узган ел амбарларга 831 мең тонна гына иген кайтты. Ләкин аны үстерү генә түгел, иң мөһиме – аннан алынган керем, тырышлыкның бәрәкәтен күрү, бурычларны каплау. Кызганыч, узган ел фермерлар табыш кертә алмады. Җитмәсә, февральдән сөт бәясе төшкән иде. Нәтиҗәдә кече һәм урта авыл хуҗалыгы оешмалары сөт сатудан аласы 7 млрд сумнан артык акчаларын югалтты. Игенне дә санасак, бу югалту 15 млрд сумга кадәр җитә. Шуңа күрә без 2024 елга шәп кәеф белән керә алмадык. Бик авырга туры килде. Шунлыктан, күп кенә шәхси хуҗалыклар терлекләрен бетерде, фермерларның 15–17 проценты эшләрен туктатты. Шулай булса да, алар 128 млрд сумлык продукция җитештерде, ягъни бу – барлык күләмнең 44 проценты дигән сүз. 2023 елда республиканың барлык төр хуҗалыклары 2 млн 198 мең тонна сөт савып алды. Шуның 700 мең тоннасы шәхси хуҗалыкларга һәм фермерларга туры килә. Тик без бюджет ярдәменең 17 процентын гына алдык. Эре агрохолдингларга ярдәм безгә караганда биш тапкыр күбрәк тия. Ни өчен шулай булуы безгә аңлашылмый.

:: Бу проблемалар турында фермерлар инде берничә ел әйтеп килә. Әсезнең әлеге мәсьәләгә карата фикерегезне республика җитәкчелегенә җиткергәнегез бармы?

– Минем мөрәҗәгатьләрнең, язган хатларның исәбе-хисабы юк. Кайсыдыр мәсьәләләрдә уңышка ирешелә, кайсыларынадыр әлегә тиешле игътибар бирелми.

:: Ничек уйлыйсыз: фермерлар авылның тоткасы була аламы, авылны саклап калуда аларның роле ни дәрәҗәдә зур?

– А.А. Никонов исемендәге Бөтенроссия аграр проблемалар һәм информатика институты соңгы ун елга авыл яшәешенә анализ ясаган. Алар эре индустриаль терлекчелек комплекслары һәм мегафермалар төзегән җирлекләрдә депопуляция тизләнгән, дигән нәтиҗәгә килгән. Моннан тыш, агрогигантлар банкротлыкка чыккан очракта, якын-тирәдәге авылларда яшәүчеләрнең тулысынча диярлек эшсез калуы ихтималы зурая. Шул ук вакытта тикшерену нәтиҗәләре гаилә фермалары күп булган, азык-төлек җитештерү, эшкәртү һәм сату белән шөгыльләнгән районнарда халык саны сакланып калуын күрсәткән. Фермерлар авылга зур үзгәреш кертте. Заманында аларга ышанмау, авылны бетерүчеләр дип карау да бар иде, ләкин еллар узган саен, киресе дәлилләнде. Көчле фермерлары булган авылларның киләчәге өметле.

:: Тик, кызганыч, андый авыллардан да халык шәһәргә агыла.

– Безне иң нык борчыганы да – халыкның авылдан китүе. Бүген анда яшәүчеләрнең нибары 25 проценты гына – эшкә яраклы яшьтә. Халык авылдан китмәсен өчен, комплекслы программа булдырырга, кешегә эш бирергә кирәк. Ә аны ничек булдырырга? Җиргә, дәүләт ярдәме аз булса да бар. Шуңа күрә 2023–2033 елларда Татарстанда 35–40 мең фермер хуҗалыгы оештыруны максат иткән программага керү инициативасы белән чыктык. Безне ишетерләрме – анысын вакыт күрсәтер.

«Татар-информ»

:: Хәрби операция, санкцияләр фермерларның эшчәнлегенә ничек йогынты ясады? Фермерлар яңа шартларга җайлаша алдымы?

– Фермер хуҗалыкларының барысында да диярлек үзебезнең техника эшли. Санкцияләргә кадәр дә шулай иде, хәзер дә. Ә Россия техникасын без «Росагролизинг» оешмасыннан алабыз. Алар белән фермерлар өчен уңышлы шартларда килешү төзедек. Орлыклар белән дә авырлык юк. Кемдер сатып ала, кемдер үзендә җитештерә. Шуңа күрә фермерлар язы чәчүгә үз көчләре белән әзерләнә.

:: Авыл хуҗалыгында ашлык күп булса – бәясе юк, сатып булмый, аз булса, бәясе кыйммәт. Алтын урталыкны ничек табарга соң?

– Хуҗалык уңышлы эшләсен өчен, рентабельлек 20–30 процент тәшкил итәргә тиеш. Әгәр юк икән, аңа кадәр эшләгән эшләренең файдасы булмый. Бу хәл бер-ике ел рәттән кабатланса, банкротлыкка чыгарга яки ябылырга мәҗбүр булачаклар. Шуңа күрә дәүләт алынмый калган табышны субсидия итеп бирергә тиеш. Теләсә нинди эшмәкәрнең кереме булган кебек, фермер да ярлы булырга тиеш түгел. Әгәр фермер билгеле бер баш терлектән билгеле бер күләмдә сөт савып ала алмый, саткан продукциясенең хакы юк икән, рентабельлек каян булсын? Кызыклы саннар китерәм: авыл хуҗалыгына кергкән 1 сум акча 90 тиен табыш китерә. Эшкәртүдә исә һәр керткән 1 сумга 7 сум керем алына. Әгәр сатуны да алсак, 1 сум 15 сумга кадәр табыш китерергә мөмкин. Шуңа күрә без, кооперативлар оештырып, эшкәртүгә һәм сатуга басым ясыйбыз.

:: Терлекчелек һәм игенчелек юнәлеше буенча эшләүче фермерлар күп. Соңгы елларда нинди яңа юнәлешләр барлыкка килә?

– Соңгы елларда яшелчәчелек белән шөгыльләнүче фермер хуҗалыкларына ярдәм чаралары артты. Балыкчылык, авыл хуҗалыгы кооперативларына да игътибар бирелә. Соңгылары 2022 елда – 15 млрд сумлык, узган ел 14,7 млрд сумлык азык-төлек җитештерде. Тормышка ашмаган проектлар да бар. Әйтик, Зәйдә агросәнәгать паркы ачкан идек тә, ул уңышлы эшләп китә алмады. Совет заманында җитештерүне шәхси хуҗалыклардан тартып алып, читкә чыгару безнең зур хатабыз булды. Аларны авылдан читкә чыгарырга кирәкми иде. Андый очракта авылда сыер савучылар белән мал караучылар гына түгел, югары квалификацияле белгечләр дә калыр иде. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, Татарстанда 446 кооператив формалашкан, ләкин аларның 181е генә эшли. Кемдер акчага кызыгып килде дә туктатып калды. Кемдер шәхси максатларын күзаллап керде. Кооперацияләр исә Кукмара, Саба районнарында күп. Буа, Чүпрәледә дә актив эшлиләр. Ә менә Әтнәдә бер генә кооператив бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Саннар

- **20** елда авылдан **102** мең кеше киткән. Районнар буенча уртача алсак, **13** мең кеше дигән сүз.
- Авылдан китүчеләрнең **58** проценты – яшьләр **(15–39 яшь)**. Китүче хатын-кызлар ир-атларга караганда **4** тапкыр күбрәк.
- Бүгенфермер хуҗалыкларында **107** мең баш мөгезле эре терлек исәпләнә, аларның **38,6** меңе – сыерлар.
- Татарстанда **4** меңнән артык фермер хуҗалыгы бар.
- Шәхси хуҗалыкларның **86** процент җире – фермерларда.

БИШ БАЛА ӘНИСЕ:

«Аларга карап сөенәм»

2024 гаилә елы

Апаста яшәүче Рамилә Әхмәтҗанова узган елның ноябрендә «Герой-ана – 2023» Россиякүләм бәйгесендә җиңеп чыга. Бу бүләкне «Хатын-кызлар көче берлеге» иҗтимагый оешмасы күп бала тәрбияләп үстергән һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашкан аналарга тапшыра. Бәйгегә Россиянең төрле төбәкләреннән катнашырга теләк белдереп 426 гариза килгән була. Рамиләгә Мәскәүдә узган зур тантанада күкрәк билгесе һәм бүләкләр тапшыралар. Биш бала әнисе өчен зур бәйгедә җиңү көтелмәгән сөенеч була. Ул ахыргача, безне кем уздырсын анда, дип йөри.

© Анна Араханія / syuyumbike.ru

– Район ЗАГС җитәкчелеге, әйдәгез, бер бәйгедә катнашыгыз әле, дип шалтыратты. Гаиләбез турында мәгълүмат кирәк иде. Кеше алдында яхшы түгел, дип кенә сорагаинарны җибәрдем. Июль ае иде бу. Катнашуыбыз хакында онытттык та. Берзаман октябрь аенда телефонга, Мәскәүгә килә аласызмы, дигән хәбәр килде. Безнең гаилә җиңүчеләр исемлегендә иде, – дип искә ала Рамилә. – Әле минем Мәскәүгә дә барырга исәбем юк иде. Апам Раниягә сөйләп күрсәтүем булды, ул тиз арада тәртипкә салды. 7 айлык баламны алып, аны карашырга дип икебезнең дә олы кызларыбызны иярттеп, Мәскәүгә кузгалдык.

Рамилә белән Ришат 2017 елның май аенда гаилә корып җибәрә. Очрашып йөрүләренә җиде генә ай булса да, алар бер-берләренең башка яши алмауларын аңлый. Бүген олы уллары Ранилгә – 15, Ралинәгә – 12, Раминәгә – 8, Раидәгә – 5 яшь, Равилгә 10 ай икән. Алар гаиләсендә хикмәтле сан да бар. 25 числосы бәхет китерә үзләренә. Рамиләнең 25 февральдә туган көне, Раминә исемле кызы да шул көнне туган. Кечеләре дә апрельнең шушы числосында дөньяга аваз салган.

– Ирем дә, мин дә өч балалы гаиләдә үстек. Дүртенче балага авырлы икәнне белгәч, ирем, тап, диде. Бишенчегә тагын бер малайлы булыйк, дип бардык. Ирем бик тә бала җанлы. Өйдәгеләрне генә түгел, урамдагы сабыйларны да кочаклап ала ул, – ди Рамилә. – Күпбалалы гаиләдә бер дә күңелсез түгел. Олыраклары кечеләрен караша. Бердәм, дус, тату булып үсәләр. Олы кызыма кечесен калдырып була. Бөтен эшне балалар белән бергә башкарабыз. Алар да кул арасына керсен, дим. Кызларым камыр ризыклары да пешерә белә инде. Аны миннән дә матуррак итеп бөгәләр.

Ранилнеке егетләрчә. Ул алты яшеннән хоккей белән шөгыльләнә, былтыр әле үзен Казанның «Ак буре» командасына чакырган булганнар. Әтисе ел буе улын Казанга тренировкаларга йөрткән. Быел 9 нчы сыйныфта укуын исәпкә алып, кире Апас командасына кайткан. Олы кызлары да спортны ярата икән. Мәктәпнең волейбол командасында уйный. Рамилә дә яшь вакытта волейбол уйнаган. Менә хәзер аның тренеры кызын өйрәтә икән. Уртанчы кызлары сәхнәне ярата. Бию түгәрәгенә йөри, матур итеп җырлый. Раидәләре бакчада әле.

– Бишесенә биш төрле холык. Әмма шулай да балалар турында начар сүз ишеткәнебез юк. Алга таба да шулай булсын инде. Иң мөһиме – алар кешелекле, ярдәмчел булып үссеннәр. Апа-абый, эне-сеңелләренә терәк булсыннар иде. Күңелендә игелек, яхшылык булса, барысына да ирешәсең, – ди Рамилә. – Ирем белән әзергә-бәзәр тормыш башлаган кешеләр түгел без. Шуңа хәзерге тормышыбызга шөкер итәбез. Һәр бала үз ризыгы белән туа, диләр. Дөрес ул. Әле бит гаилә корганда ипотекага ике бүлмәле фатир алган идек. Ике елдан аны сатып, йорт алдык. Икәү бергә тапкан мал булгач, бик рәхәт. Тапкан малның кадере бар. Ә менә балаларга ничек тә ярдәм итәсе килә. Бишесе дә газиз. Кулдан килгәнне эшләрбез, калганын үзләре булдырырлар дип ышанам. Шулай итеп тәрбияләргә тырышабыз инде.

Рамилә гаилә бәхете хатын-кыз кулында икәнне белә. Әнә шуңа да өй җылысын саклар өчен барысын да эшли. Үзенә үрнәк итеп куярлык әтисе белән әнисе бар. Җылы ояда тигез канатлы булып үскән кызчык үз балаларына да шуны теләр. Дөньялар тынычлансын. Ире Ришаты махсус хәрби операциядәге якташларына инде җиденче мәртәбә ярдәм илткән. Егетләр арасында Рамиләнең бертуган энесе Ранис та бар. Бөтен гаиләләре белән аның исән-сау әйләнеп кайтуын көтә алар. Менә шунда бәхетләре тагын да тулгәрәкләнер иде.

Бу арада Әхмәтҗаннар өйләренә ремонт ясый. Шундагы шау-шуга, бергә эшләүгә дә сөенә Рамилә.

– Обойлар ябыштырабыз, бүлмә ишекләрен алыштырабыз. Иң кечкенә кызыбыз диварны буйый, Ранилем обой куптара. Ришатым ишекләрне сүтә. Ралинәм энесен күтәреп йөри. Мин аларга тәмле ризык әзерлим. Раминәм янымда бөтерелә. Менә мантый пешеп чыга. Бөтенесе, әни тәмле пешергән, дип рәхмәт әйтә. Мин исә әтиегез турап биргән тәмле иттән булганга ул, дим. Балаларымның барысына да рәхмәтемне җиткерәм, – ди Рамилә. – Менә кайда икән ул бәхет! Аллаһы Тәгалә бәхетебезне күпсенмәсен. Сәламәтлектән аермасын. Ә калганын булдырырга була.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КҮҢЕЛ ДӘ ПАКЬЛӘНӘ

Рамазан – сәгадәт ае, айларның солтаны. Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров мөселманнарның иң көтеп алган аен әнә шулай дип атый. Адәм баласынын бик нык рухи әзерлек, ихтыяр көче соравы белән дә кадерле ул.

Быел рамазан ае 10 мартта кояш баеганнан соң керә. 11 март – уразаның беренче көне. Беренче тәравих намазы 2024 елның 10 мартында да ястү намазыннан соң укыла, соңгысы – 8 апрельдә. Быел мөселманнар барлыгы 30 көн ураза тотачак. Ураза бәйрәме 10 апрельгә туры килә.

– Ошбу рамазаныбызның көннәре бер бәрәкәт булса, кичләре – бер бәрәкәт. Безнең бердәмлегебезне арттыра, кардәшләрне күрештерә, мохтаҗларның хәлләрен белергә өйрәтә торган, ризыклы булган, ярдәмчелеккә юл ачкан сәгадәт аебыз, – дип сөйләде Равил хәзрәт журналистлар белән очрашуда.

Мөфти урынбасары сүзләренә караганда, республикакүләм ифтар быел федераль дәрәҗәгә чыга. Равил Зөфәров бу уңайдан да ачыклык кертте:

«Быел республикакүләм ифтар 29 март көнне «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында уза. Уникенче тапкыр үткәрәләчәк чарада 12 мең кеше катнашачак. Быелдан башлап илебездәге иң зур авыз ачу мәҗлесләренең берсе «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме канаты астында үткәрелачәк. Чарага кунсанлы дәрәҗәле чит ил кунакларын чакыру ниятләнә. Ифтарда дөньякүләм танылган Коръән укучылар һәм нәшид башкаручылар катнашачак».

Быелгы ифтарны оештыруда 700 волонтер ярдәм итәчәк. Анда катнашу өчен (843) 237-86-18 телефон номерына шалтыратырга кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

- ✓ **Нәзарәтнең Голәмәләр Шурасы һәм Казыйлар Шурасы карары белән, быел фитыр сәдакасын түләү өчен нисаб күләме – 43000 сум (көмеш буенча), зәкят чыгару өчен нисаб күләме – 495000 сум (алтын буенча) билгеләнде.**
- ✓ **Фитыр сәдакасы арпа буенча исәпләгәндә – 150 сум, йөзем белән исәпләгәндә – 1000 сум.**
- ✓ **Моннан тыш, сәламәтлеккә бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаган һәм аны башка вакытта да, каза кылып, үти алмаучылар өчен тотылмый калган һәр көн өчен 400 сум күләмендә фидия билгеләнде.**

Ай дәвамында республика мәчетләрендә дә ифтар мәҗлесләре узачак. Казанда ул 46 мәчеттә үткәрелачәк. Аларның исемлеге белән нәзарәт сайтында (www.dumrt.ru) танышырга була. Ифтарларны үз исемеңнән оештыру өчен күрсәтелгән мәчетләрнең имамнарына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әлеге мәчетләргә ифтарларга килергә теләүчеләргә алдан язылырга кирәк.

Рамазан – игелекләр ае. Бу уңайдан республикада елдагыча «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны узачак. «Зәкят» фонды җитәкчесе Булат Мәрданов сүзләренә караганда, фонд аша ярдәм алу өчен (843) 225-33-22 номерына шалтыратып мөрәҗәгать итәргә кирәк. Фонд вәкилләре, махсус документлар соратып, аның дөрестән дә ярдәмгә мохтаҗ булуын тикшерәчәк. Мохтаҗ дип табылса, кешегә ярдәм шундук күрсәтеләчәк, йә булмаса, ул чиратка куелачак. Мохтаҗларга ярдәм итәргә теләүчеләр исә бу ният белән чыгга ашыру юллары турында тулырак фонд сайтында (www.zakyatrt.com) белә ала.

– Рамазан аенда оештырылган акция кысасында без 20 авыру баланың дәвалануы өчен акча күчерергә ниятлибез. Моннан тыш олы яшьтәге 20 мохтаҗ кешегә дә акчалата ярдәм күрсәтергә планлаштырабыз. Авыру, ярдәмгә мохтаҗ кешеләр безгә даими мөрәҗәгать итеп тора. Үзебезнең база бар. Анда республикабызда яшәүче 1 меңгә якын гаилә исәпләнә, – дип сөйләде Булат Мәрданов.

Динә ГЫЙЛӘҖИЕВА

Уразага бәйле 4 сорау

:: Фидия, фитыр сәдакаларын рамазан ае тәмамлангач та тапшырырга ярыймы?

– Бу сәдакаларны рамазаннан соң тапшырсагыз да була. Шулай да фитыр сәдакасы рамазан аенда, гаеткамазына кадәр бирелеп бетсә, хәерләрәк. Юкса, ул кеше өстендә вәҗиб булырак калачак. Фитыр сәдакасын «Зәкят» фондына да тапшырырга мөмкин. Ул фәкыйрьләрнең вәкиле булып тора. Шуңа күрә бу очракта фитыр сәдакасы вәкилгә тапшырылган көннән түләнгән санала.

:: Тәравих намазын мәчеттә уку саваплыракмы әллә өйдәме?

– Ир кешегә тәравих намазын җәмәгать белән уку фазыйләтлерәк. Хатын-кызлар исә күрем вакыты булмаган көннәрдә әлеге намазны мәчеткә барып укый ала. Шулай да йортында укыса, ул хатын-кыз өчен фазыйләтлерәк була.

:: Тәравих намазын 20 урынына 8 рәкәгать кенә укысаң да ярый, диләр. Алай эшләү дөресме?

– Тәравих намазын 8 рәкәгать кенә укый икән, кеше моның өчен әҗер-савабын азрак алачак. Тиешенчә, 20 итеп укысаң, әҗер-савабы күбрәк була. Ләкин әгәр кеше, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, тәравих намазын сигез рәкәгатьтән арттыра алмый икән, бу очракта алай эшләүнең зыяны юк.

:: Кадер кичәсен рамазан аеның соңгы ун көнендә эзләргә кирәк. Әмма дини бәйрәмнәр һәм истәлекле даталар календарендә аның төгәл көне куела. Бу ни өчен шулай эшләнә?

– Календарьдагы Кадер кичәсе көне якынча гына куела. Бу безгә Кадер кичәсен эзләмәс өчен сәбәп түгел. Аллаһы Тәгалә, без аның дәрәҗәсен, һәрбер кичәнең кадерен белсен, һәр кич тулы гыйбадәт кылсын өчен, аны рамазан аеның соңгы ун көненә яшергән.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Алгарышмы, алдагычмы?

Халыкара истәлекле даталар арасында Инженерия көне дә бар. Аны һәр елның 4 мартында билгеләп үтәләр. Әлеге датаны инженерлар, уйлап табучылар, конструкторлар, техник, технологик юнәлештә эшләүче галимнәрнең һөнәри бәйрәме дип атарга да буладыр.

Без техник һәм технологик алгарыш бер көнгә дә туктап тормаган уникаль чорда яшибез. Яшәгән саен тормыш-көнкүреш яхшыра: өйләребездә эшне җиңеләйтүче, тормыш сыйфатын яхшыртучы нинди генә җиһаз-җайланмалар юк бүген. Бүлмә буйлап үзе йөрүче тузан суырткыч, табак-савыт юу машиналары инде кичәге көн. Халык хәзер тәрәзә юучы роботлар, акыллы суырткычлар сатып ала башлады. Кая барсак та, кесәләребездә телефон – дөньяның теләсә кайсы ноктасына хәбәр җибәрергә, җир читендәге кеше белән дә элемтәгә керергә мөмкин. Электр энергиясен дә без хәзер мәңге булган һәм булачак бер уңайлык дип кабул итәбез. Бер атнага, юк, бер генә көнгә электрсыз калуның да тормышны параличлаячагын белмибез, белергә дә теләмибез. Халыкның күбесе аның ничек яралганын да белми, гидроэлектростанциядәге турбинаны, АЭСтагы атом реакторын күз алдына да китерми. Ул мәҗбүри дә түгел. Ләкин шул җиһазлар үз вакытында уйлап табылмаган булса, әле бүген дә, бәлки, кичләрен шәм кабызасы булыр иде. Инженериянең, техник фикернең янә дә бер казанышы – автомобиль дә тормышыбызга шул тикле үтте, ансыз бүгенге көнне дә, иртәгәне дә күз алдына китермибез…

Инженерия көнен гамәлгә йөздән артык илне берләштергән Бөтендөнья инженерлык федерациясе куйган. Федерациягә 30 миллионлап белгеч керүен язалар. Бу – планетаның инженерлар армиясе – көн туса, нидер уйлап табып, камилләштереп, җитештереп, дөньяны үзгәртеп торучылар. Россия инженерлары да ул армиянең берничә дивизиясен тәшкил итә. Инженер ул – фәнни хезмәткәр белән җитештерү өлкәсе арасында торган арадашчы. Нинди дә булса физик күренешне ачу галим-голәмә эше булса, ачышны куллану, аңа нигезләнгән яңа җиһаз-җайланмалар булдыру – инженер эше.

Бу юллар авторының хәтсез гомере инженер вазыйфаларын башкарып үтте. Инженер-технолог булып башланган хезмәт стажына инженер-конструктор, инженер-электронщик вәкаләтләре өстәлде. Соңгы ике вазыйфа күңелгә аеруча якын булды. Конструктор дигәндә, без хезмәт куйган берәмлек Механизация һәм автоматизация бүлеге дип аталып, аның үз конструкторлык бюросы, конструктор сызган-бозганны металлга ирештерүче цехы да бар иде. Предприятие җитештергән продукция исемлеге зур, күп процессларга автоматика, механикалаштыру әле барып җитмәгән. Җитештерүдә эшләгән кеше белә: механизация аз булу хезмәт җитештерүчәнлеген түбәндә тота. Безнең бурыч шул җитешсезлекне булдыра алган кадәр бетерүгә юнәлтелгән иде. Күпчелек очракта ике өлештән – механикадан һәм аның белән идарә итүче электрон блоктан торган җайланманы булдыру җиңел хезмәт түгел. Һәр ике өлкәне дә яхшы белергә кирәк. Ә инде син айлар буе тырышып кәгазьдә хәстәрләгән, тимер конструкциягә әйләнгән җайланманың төп цехларның берсендә эшләп китүе һәрчак олы сөенеч китерә, горурлык хисе уята иде.

Хәзер уйлыйм: бәлки, азрак горурланасы булгандыр. Ни өчен дигәндә, мин хезмәт куйган предприятие оборона сәнәгатенә карый иде. Менә шушы урында без инженерлык хезмәтенең бик үк мактаулы булмаган ягына да караш ташларга мәҗбүрбез. Чөнки алда телгә алынган инженерлар армиясенең зур өлеше, гыйлемле өлеше бүген төрледән-төрле корал системалары булдыру, аларның яңаларын уйлап табу юнәлешендә эшләргә мәҗбүр. Бу хәл без яшәгән илгә генә түгел, ярты дөньяга кагыла. Меңләгән, дистә меңләгән белгечнең акылы кирәкмәгән, гөнаһлы юнәлешкә хезмәт итә. Миллиардлар белән исәпләнгән суммалар түгелә. Иң сәләтле галимнәр, иң булган инженерлар мантыйк кабул итмәгән, аек акыл аңламаган эш майтара…

Әйе, кемдер «Тынычлык теләсәң, сугышка әзерлән» дигән кагыйдәнең барлыгын искә төшерер. Без шулай эшләргә мәҗбүр, дияр. Тик ни өчен XXI гасырда да кешелек борынгы Рим заманыннан калган постулатны үз итеп яшәргә тиеш соң әле? Дөнья үзгәрергә, яхшыланырга тиештер ләбаса. Инде язмадык түгел, яздык: рухи, әхлакый үсеш тизлеге түбән булганда, кешелек ул өлкәдә урында таптанганда, техник алгарыш, ашкын техник прогресс безне фаҗигагә җиткерергә дә мөмкин ич. Корал ясау, яңартуда эшләүче инженерлар армиясе, бер сәгатькә дә туктамаган фәнни-техник эзләнүләр тыныч тормышка юнәлтелсә, без бүген гел бүтән дөньяда яшәмәс идекме? Инженериянең, фәннең корал коюга юнәлгән өлешен, анда күпме генә ачышлар булса да, алгарыш сүзе белән атау – хата, миңа калса.

Беренче эш кораллары, ук белән җәя ясаудан башланган техник фикер техник һәм технологик цивилизация тудырды. Яши-яши, рухи як аксау сәбәпле, без әйләнә-тирә табигатьне пычраттык, флора белән фаунага тиңдәшсез зыян салдык, техноген һәлакәтләр дип аталган яман күренешләрне тудырдык, атом-төш сугышы куркынычын юктан бар иттек. Кеше дигәнебездә техникага, уңайлыкларга бәйлелек барлыкка килде, гиподинамия дигән хаста яралды. Без үзебезнең табигать баласы булганлыгыбызны оныттык кына түгел, аның белән конфликтка да кердек. Саналган бәлаләрдән котылу өчен, бәлки, техник прогрессны, аның юнәлешләрен контрольдә тотучы халыкара оешма кирәктер? Бәлки, техник алгарышны акрынайту, хәтта туктатып тору зарурдыр?..

ШЕШӘДӘ – АГУ

Яшәеш

Шәһәрдә подъезд төбендәге эскәмиядә әбиләр утыру – гадәти хәл. Бездә дә бар алар. Гел өчәү-дүртәү җыелышып, нидер турында гәпләшәләр. Ара-тирә ялтыр-йолтыр яулык япкан әбиләр алышына: берсе урынына икенчесе утырмага килә. Арада гел «сакта» торучы бер әби дә бар. Беренче катта яшәүче Вәфирә апа (исеме үзгәртелде. – Авт.) постны бирми. Без эштә булган арада, мәктәпкә баручы-кайтучы балаларны сәлам биреп каршы ала, озата. Тик беркөнне улым шаккатып шалтырата: «Күрше әби урамда егылып йоклап ята...» Исерек икән, дип тә ишеткән...

Илдар Мөхәммәтҗанов

…Үзе сер бирмәсә дә, Вәфирә апаның ире сөйләде: хатын-кыз яшьлегендә үк кибеттә эшләгәндә, чәркә күтәрә башлаган. Өченче балалары инвалид булып тугач та, шешәдә юаныч эзләгән. «Шулай итеп, төнлә тынычлап йоклау өчен, бер-ике чәркә хәмер күтәреп кую гадәти хәлгә әйләнде», – дип искә алды күршебез. Дәвалаганнар, бер тапкыр гына да түгел. Әллә шуның файдасы тигәнме, әллә яшь белән акыл кергәнме, соңгы унбиш елда өйдә хәмерне бәйрәм табынына да куймаганнар. Тик чәченә чал кергән әби кабат «яшел елан» тозагына эләккән. Сәбәбе: шәхси йортта янгын чыгып, уллары янып үлгән. Әнисенең хәленнән килмәгәч, ир-атның өчесен һәм җидесен дә күрше-күлән әбиләр укыткан…

Сер түгел, хатын-кыз эчкече булудан да яман һәм куркыныч нәрсә юк. Әгәр әни сәрхуш икән, бу ахырзаманга тиң. Гаилә таркала, балалар ятим кала. Рәсми саннар да юатырлык түгел. Моннан биш ел элек барлык эчкечеләрнең 5 проценты хатын-кызларга туры килсә, хәзер әлеге сан – 30 процент.

Былтыр күбрәк тә эчелгән. 2023 елның сигез аена алынган мәгълүматларга караганда, республикада яңа туган балаларны да кертеп, җан башына 9,2 литр алкоголь эчемлек сатылган. Сыраны исәпкә алмыйча бу! Сату-алулар Казанда күбрәк. Беренче өчлеккә Әлмәт районы һәм Чаллы да эләккән.

Татарстанда 2015 елдан бирле «Аеклык ноктасы» социаль проекты эшли. Аның кысасында, нигездә, ана булу хокукыннан мәхрүм ителү мәсьәләсе каралган, балигъ булмаган балалар әниләре алкоголизмнан дәвалана. Парлап килүчеләр дә бар. Мәҗбүри түгел, әлбәттә. Проектта катнашучылар дәвалану курсын узып бетергәч тә, күзәтү астында кала. Аларга психологик ярдәм күрсәтәләр, эш табарга булышалар. Бу эш балаларны социаль ятимлектән йолып калу өчен эшләнә.

– Быел авыр тормыш хәлендә калган 185 гаиләгә ярдәм итәргә тырышабыз. Аларның күбесе 45тән яшьрәкләр. Проектта республиканың барлык районнары да катнаша, – диде Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокуклары буенча республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе Илсөяр Гарифуллина.

Аның әйтүенчә, ни кызганыч, барлык әти-әниләр дә үз теләкләре белән эчүчелектән баш тартырга әзер түгел. Шуңа күрә күпме генә тырышып та, ахыр чиктә балаларны гаиләдән тартып алырга туры килгән очраклар да бар.

– Проект кысасында, эчүчелектән котылырга теләүчеләргә, иң беренче чиратта, наркологлар ярдәмгә килә, – ди Татарстан сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Абашев. – Районнардагы табиб-наркологлар һәм республика наркология диспансеры белгечләре эшли. Безнең максат – хәмердән тулысынча баш тарту. Моңа төп сәбәп – ата-ана булу хокукыннан мәхрүм ителү куркынычы.

Былтыр 106 гаилә, аларның алтысы – парлар, проектта катнашкан.

– Дәвалый башлаганда, аларның яртысыннан күбрәгенең эш урыннары да юк иде, – дип искә алды Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Юлия Абдреева. – Балалар бакчасына йөрмәгән 30 сабыйны бакчага урнаштырдык, 45 кешегә социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерергә булыштык. 63 кеше эшле булды. Тагын берсе Казанда дәвалану курсын узып бетермәгән әле, аңа эш табарга булышу өчен, Чистайга әйләнеп кайтуын көтәбез.

> **Венера КАСЫЙМОВА, психолог:**
> – Алкоголизм – хроник авыру. Шуңа күрә аны бөтенләй дәвалап бетереп булмый. Бигрәк тә, хатын-кызларда. Шул ук вакытта, ир-атлар белән чагыштырганда, гүзәл затлар эчүчелеккә икеләтә тизрәк сабыша. Нишләргә? Алкоголь эчеп кенә ял итеп була, дип фикер йөртү – зур ялгышлык. Кәеф-сафа кору өчен хәмер кирәкми. Якын кешегезнең шешәгә үрелә башлавын сизсәгез, аның белән сөйләшегез, бу гамәлнең нәрсәгә китереп җиткерергә мөмкин булуын аңлатыгыз. Белгечкә барырга киңәш итегез.

Әйтүләренә караганда, проект пациентларының 75 проценты туры юлга баса. Иң мөһиме, балалар ана назыннан, гаилә җылысыннан мәхрүм ителми.

…Балалар подъезд тирәсендә эленке-салынкы йөрүче, үткән-киткәннән акча сораучы Вәфирә апаны читләтеп кенә узарга күнекте. Бу кыш башында гомумән күренми башлады ул. Соңыннан гына белдек: ашказаны авыруы көчәеп үлгән. Соңгы чиккә җиткән әбигә табиблар да ярдәм итә алмаган…

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Дәүләтшина** Дания Салих кызы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Хәлиуллин** Рәшил Сөләйман улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов район суды судьясы **Газизова** Руфина Дарвин кызы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов район суды судьясы **Галимова** Лилия Галимхан кызы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының оештыру ягыннан үстерү бүлеге әйдәүче белгече **Гыйззәтуллина** Динә Динис кызы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасының куркынычсызлык идарәсе җитәкчесе **Нургалиев** Динар Фарил улы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Салихҗанов** Ирек Фаяз улы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Нурлат-информ» филиалы баш мөхәррире – җитәкчесе **Гыйнәева** Резеда Әкрам кызы, мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Богородский урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең химия һәм физика укытучысы **Зарипова** Розалия Абдулкабир кызы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе урынбасары **Захарова** Светлана Николаевна, актив иҗтимагый эшчәнлеге, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Аксубай муниципаль районының сугыш һәм хезмәт ветераннары җирле иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Ильмухин** Александр Степанович, хезмәтендә уңышларга ирешүе һәм күп еллар дәвамында нәтиҗәле эшләве өчен «Топливосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Мифтахов** Гали Ибраһим улы, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Нәбиуллин** Фирдәүс Рафаил улы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы **Низамова** Ләйсән Габделхан кызы, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Балык Бистәсе пассажир автотранспорты предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хөснетдинов** Илфат Миңнулла улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Галиуллин** Алим Мәгъсүм улына **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Кама Тамагы коммуналь челтәрләре» ачык акционер җәмгыятенең су-канализация хуҗалыгы мастеры **Айтуганов** Данир Баграм улына, «ЖЭК-42» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте санитария-техник җиһазларның эчке системаларын монтажлаучысы (Казан шәһәре) **Әхмәдуллин** Хәлил Әһлиулла улына, «Азнакай җылылык челтәрләре предприятиесе» акционер җәмгыятенең экскаватор машинисты **Гайнуллин** Сирин Наил улына, Мамадыш муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесенең төзекләндерү буенча инспекторы **Гыйниятова** Зөлфия Вәлиулла кызына, «ЖЭК-14» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең урам җыештыручысы (Казан шәһәре) **Кореева** Анна Григорьевнага, Казан шәһәренең «Шәһәр күперләре» муниципаль унитар предприятиесенең төзелеш маляры **Сафиуллина** Миләүшә Исмәгыйль кызына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесенең сүүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы бүлеге баш белгече **Торшина** Ольга Гарриевнага **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Балтач муниципаль районының «Балтачның үзәкләштерелгән авыл клублары системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Балтач мәдәният үзәге сәнгать җитәкчесе **Атабаева** Наилә Әсхәдулла кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Бариева** Диларә Мөбарәкша кызына, «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (Чаллы шәһәре) **Гайнуллина** Венера Марсил кызына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Бакиров исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Казакова** Әлфия Рифкать кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы **Касыймова** Гөлнара Йосыф кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы – Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең 1 номерлы филиалы – М.Җәлил исемендәге мәдәният йортының «Зифа каен» халык вокаль ансамбле аккомпаниаторы **Муллаянов** Зәйтүн Бахер улына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы **Мостафина** Эльвира Ринат кызына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Ә.Бакиров исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Новикова** Татьяна Николаевнага, «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең методика-библиография бүлеге мөдире **Сабирова** Ләйлә Рәхим кызына, Кама Тамагы муниципаль районының «Авылара үзәк китапханә» муниципаль бюджет учреждениесенең 15 номерлы филиалы – Кече Салтык авылы китапханәсе әйдәүче китапханәчесе **Сабирова** Рәсимә Солтан кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы – Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең 1 номерлы филиалы – М.Җәлил исемендәге мәдәният йорты хореографы **Савельева** Мария Николаевнага, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Старкова** Наталья Геннадьевнага, «Әлки район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең автоклуб мөдире **Смышляев** Сергей Павловичка, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Ә.Бакиров исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Шәйморатова** Резеда Рәшит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «5 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Баһаутдинова** Венера Атлас кызына, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Хәмидуллин** Илмас Илдар улына, «София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Гарифуллина** Ләйлә Илдар кызына, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты гомуми тәэминат һәм эш башкару бүлеге башлыгы **Якупова** Светлана Владимировнага, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе кризислы хәлләрдә идарә үзәге башлыгы **Александров** Александр Александровичка, Казан эзләү-коткару отряды («Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Идел буе төбәк эзләү-коткару отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы) коткаручысы **Кудряшов** Дмитрий Григорьевичка, Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы административ-хуҗалык бүлеге башлыгы **Сәйфуллин** Марс Әмирхан улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Ютазы районы буенча бүлеге бүлекчәсе өлкән инспекторы (административ законнарны үтәү буенча), полиция өлкән лейтенанты **Абдуллин** Илмир Ирек улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы экстремистлыкка каршы көрәшү үзәгенең Казан зонасы (Казан шәһәрендә урнашкан) милли һәм дини җирлектә экстремистлыкка каршы көрәшү бүлеге аеруча мөһим эшләр буенча оперуполномоченные, полиция өлкән лейтенанты **Бикушев** Виталий Владимировичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы эксперт-криминалистика үзәгенең криминалистик экспертиза һәм җинаять булган урыннарны карап тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Ермакова** Альбина Владимировнага, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге җинаятьчеләрне эзләү бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные, полиция капитаны **Закиров** Айнур Рамил улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы экстремистлыкка каршы көрәшү үзәгенең милли һәм дини җирлектә экстремистлыкка каршы көрәшү бүлеге дини җирлектә экстремистлыкка каршы көрәшү бүлекчәсенең аеруча мөһим эшләр буенча өлкән оперуполномоченные, полиция капитаны **Измайлов** Илнар Зөфәр улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җинаятьчеләрне эзләү бүлеге урлау һәм талау очракларын ачу бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные, полиция капитаны **Минһаҗев** Илшат Фирдәвес улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 6 номерлы «Савин» полиция бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Миңнебаев** Фәнис Фәрит улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 13 номерлы «Азино-2» полиция бүлеге башлап сорау алу бүлеге башлыгы, полиция майоры **Мөхәммәтшина** Ландыш Сәгыйть кызына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы штабы башлыгы урынбасары – штаб инспекциясе башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Сафронов** Михаил Владимировичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру идарәсенең массакүләм чараларны уздырганда урамнарда җәмәгать тәртибен тәэмин итүне оештыру бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Соколовский** Дмитрий Владимировичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәте полкының 2 батальоны 1 ротасы взводы 2 бүлекчәсе полицейские, полиция өлкән сержанты **Терентьев** Артур Юрьевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе 2 номерлы «Комсомол» полиция бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлегенең полиция өлкән участок уполномоченные, полиция майоры **Хәлимов** Руслан Әхтәм улына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге башлыгы **Гәрәев** Илфир Мөнир улына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Гордеева** Надежда Витальевнага, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге башлыгы **Егорова** Надежда Ивановнага, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге башлыгы **Фәтхуллин** Илгиз Мәгъсүм улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Богомолов** Леонид Евгеньевичка, «Хәмит Мөстәкыймов исемендәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шәфигуллин** Рафаэль Гамбәр улына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының хәрби хәрәкәтләр ветераннары район иҗтимагый оешмасы рәисе **Госманов** Данил Дамир улына, «Алойл» ябык акционер җәмгыятенең 1 номерлы нефть промыселы идарә пульты операторы **Садыйкова** Ландыш Зөфәр кызына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте челтәрләргә идарә үзәгенең диспетчерлык һәм технологик идарә чаралары хезмәте башлыгы **Буравов** Александр Николаевичка, «АК БАРС Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының оештыру ягыннан проектлау һәм персоналга идарә буенча урынбасары **Данилова** Елена Юрьевнага, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе **Мөҗипов** Рәмис Габдерәис улына, Татарстан Республикасы Тукай район суды администраторы **Фоминых** Эдуард Николаевичка, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге башлыгы **Суркова** Анастасия Анатольевнага, «Әлмәт-Водоканал» акционер җәмгыятенең канализация чистарту корылмалары участогы мастеры **Ульдияров** Владимир Алексеевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

РУСЛАН ЗАКИРОВ: «ҺӘР НӘРСӘНЕҢ ЧЫН БӘҺАСЕ ВАКЫТ УЗГАЧ КЫНА БЕЛЕНӘ»

Кунак бүлмәсе

Җырны җырлап бетерер өчен генә җырлаудан ни мәгънә? Ягымлы баритон тавышлы яшь җырчы Руслан ЗАКИРОВ белән җырның мәгънәсе, җиңел һәм җитди җырлар, ашыгып яшәү турында сөйләштек. Беренче концертын Зур концертлар залында уздырырга җыенучы егет нәрсә турында хыяллана? Гомумән, хыял – нәрсә ул?

:: Руслан, балачактан башлыйк әле.

– Балачагымның күп өлеше Яшел Үзән районының Норлат авылында, дәү әнием һәм дәү әтием янында узды. 2007 елга кадәр, бер җәйне дә калдырмыйча, айлар буе шунда тора идем. Утын кисү, балык тоту, печән әзерләү – эшләнмәгән эш калмады, кыскасы. Ә 2007 елдан узган елга кадәр һәр җәем (хәер, җәем генә дә түгел) «Сәләт»тә узды. Әлеге хәрәкәт миңа бик тәэсир итте. Бүгенге дусларым, кызыксынуларым шул мохиттә формалашты, дисәм дә була.

:: Сәхнәгә ничә яшьтә чыкканың хәтердәме?

– Беренче сыйныфта булды микән соң… Анысын әни белә инде *(көлә)*. Бераздан музыкаль мәктәпкә йөри башладым. Мине башта баян классына биргәннәр иде, вокал укытучысы янына үзем бардым. Ә тугызынчы сыйныфта, шушы юлдан китәргә кирәк, дип, музыкаль көллияткә кердем. Аннары Җиһанов исемендәге консерватория… Хәзер менә үзем укыган консерваториядә укытам.

:: Сезнең өйдә нинди җырлар яңгырый иде?

– Төрлесе булгандыр. Ләкин мин Мөслим Магомаев, Марио Ланца, Хәйдәр Бигичев җырларын аеруча яратып тыңлый идем.

:: Кумирың бар идеме?

– Кемнедер идеал, кумир итеп санаганымны хәтерләмим. Хәзер дә шулай. Җыр ничек туа? Шагыйрь хис-кичерешләр кушып, ниндидер вакыйгаларга нигезләнеп, шигырь иҗат итә. Композитор шагыйрь язган сүзләрне үз призмасы аша үткәреп, тагын төсләр өсти. Артист менә шушыларны үзе аша да үткәреп, тамашачыга җиткерә. Талантлы шагыйрьләр, композиторлар булмаса, шундый бөек җырлар булмаса, талантлы артистлар да булмас иде.

:: Ягъни һәр җырның үз тарихы, үткән юлы бар. Син теге яисә бу җырны башкарыр алдыннан бу турыда уйланасыңмы?

– Музыка үзе барын да эшли ул. Син аңа үзең көйләнәсең. Минем өчен иң мөһиме – эмоция җиткерү. Ә моның өчен җырның сүзләренә игътибарлы булырга кирәк. Әйтик, «Бүләк ит син миңа җан җылысы…» – дип язган Мансур Шиһапов. Бу – гади сүзләр генә түгел. Автор безгә хис-кичерешләре турында сөйли.

> Бүгеннең иң зур проблемасы – без һәрвакыт ашыгабыз. Чабабыз да чабабыз үзебез, нәтиҗәдә эшләгән эшебез дә юк кебек. Тукталып, менә шулар турында уйлыйсы иде. Җырны җырлап бетерер өчен генә җырлаудан ни мәгънә? Текст, көй һәм син бер бөтен булганда гына тамашачы да үзен бу бөтенлекнең бер өлеше дип санаячак.

:: Кызганыч, бүген халыкка менә шундый тирән мәгънәләргә караганда җиңел, примитив дәрәҗәдәге җырлар якынрак. Бу каршылыкны ничек җиңәргә?

– Без бит инде көн саен опера да тыңлый алмыйбыз. Ни генә эшләсәк тә, ул җиңел җырлар барыбер колакка керәчәк. Һәм мин моны шулкадәр начар күренешкә санамыйм. Халык шулай ял итә. Шул ук вакытта опера карарга йөрүчеләр дә бик күп бит. Ә операга күбрәк әзерлеге һәм вакыты булган тамашачы гына. Тагын ашыгуга әйләнеп кайта инде. Безнең бит озаклап, иркенләп опера тыңлап утырырга вакытыбыз да юк.

Шулай да, халыкны, шартлы рәвештә әйтсәк, җитди җырлар тыңларга да өйрәтергә була. Бәлки, кайчан да булса музыкаль театрга нигез сала алсак, халык анда егылып йөрер? Аннан соң, моны аңлаган һәркем ни дә булса эшли ала. Мисал өчен, социаль челтәрләргә видеоязма куйганда, нигә әле Миләүшә Хәйруллинаның җырын файдаланмаска?

:: Миләүшә Хәйруллина, димәктән, «Кави-Сәрвәр» операсы турында да сөйләшик әле. Кайчан да булса без аның чын мәгънәдә бик әһәмиятле вакыйга булуын аңларбыз. Ә син ул вакыйганың бер өлеше булуыңны аңлап җиткердеңме?

– Бәяләп җиткерелмәгән вакыйгалар бик күп. Моның өчен вакыт узу кирәк. Гомумән, һәрнәрсәнең чын бәһасе вакыт узгач кына беленә. Профессиональ музыка күзлегеннән караганда, «Кави-Сәрвәр» – ул, чын мәгънәсендә, грандиоз вакыйга. Анда катнашу түгел, аны үз күзләрең белән күрү дә – бәхет.

Минем өчен генә түгел, мөгаен, бу операда катнашкан һәр кеше өчен бу зур үсеш булгандыр. Чөнки монда һәр кеше, һәр деталь роль уйнады. Безнең алда ул вакытта вакыйгаларны, геройларыбыз кичергән хисләрне ничек бар, шулай җиткерү бурычы тора иде. Ә бу – гаять зур эш.

:: Руслан, тиздән – 7 мартта син үзең дә тамашачы алдында имтихан тотачаксың. Беренчедән, тәүге концертың Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында узачак. Моның белән бик сирәкләр генә мактана ала. Икенчедән, симфоник оркестр, хор катнаша. Җиңел юл сайламагансың…

– Мин беренче концертымның сыйфатлы музыка, хор, оркестр, профессиональ музыкантлар катнашында узачагын белә идем. Дөресрәге, ул шулай булырга тиеш кебек тоелды. Нәрсә һәм кем белән башкаруымны аңлагач, аның кайда башкарылачагы да мөһим бит. Шуңа да ул нәкъ менә Зур концертлар залында узачак.

Бу идеямне консерватория дә хуплагач, башкарып чыгачагыма ышангач, менә шундый зур эшкә алындык. 55 кешедән тора торган хор, 60лап кешелек оркестр, музыкантлар… Кыскасы, бик ныклап әзерләнәбез. Мин үземнең танылмаган, күпләр өчен билгесез булган артист икәнемне беләм. Дөресен генә әйткәндә, бу мөһим дә түгел. Мин классик җырлар башкарам. Аны ротациягә бирү яки кая да булса урнаштыруның мәгънәсе бармы икән? Әмма бу концертны оештырган чакта миңа ышанган, көнне төнгә ялгап миңа ярдәм иткән кешеләр бик күп булды. Мин аларга мең рәхмәтле.

:: Бу концерт хыялың идеме?

– Хыял бит ул – чынга ашмый торган әйбер. Әти-әни, якыннар исән-сау булсын, балалар авырмасын, менә бу – хыял. Ә бу концерт – максаттыр.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Нихәл, авыл?

Егетләр шар суга

Без балачакта «шар сугу»ны ике төрле мәгънәдә аңлый идек. Өлкәннәр аны бушка вакыт уздыруга, эш калдырып йөрүгә тиңләделәр. Ә безгә, малай-шалайга, хоккей уйнау иде ул. «Шайба» дигәннәре булмаганга агач шакмакны түгәрәкләп, шомартып, шар ясый идек. Дөрес, көннәрдән бер көнне безгә агач шарны йомшак, кечкенә тупка алыштырырга туры килде.

Уенның иң кызган чагында туп, сикереп китеп, бер малайның маңгаена шулхәтле каты итеп бәрелде, маңгай шундук туп кадәр күпереп чыкты. Шиккә калдык. Безнең уенны карап торган өлкәннәр дә: «Болай булмый, малайлар, йә бер-берегезнең күзләрен чыгарып бетерерсез», – дип, агач шарны йомшак тупка алыштырырга киңәш иттеләр. Тора-бара туп урынына алка артыннан куа башладык, тик «шар сугу» дигән сүзләр шактый яшәде әле. Ул бүгенге хоккейның башлангычы, баласы сымак иде. Субаш Аты егетләре дә, еллар узып та, «шар сугу»дан туктамадылар.

Шушы көннәрдә генә бер шатлыклы хәбәр килде, туган авылым егетләре Арча районы башлыгы призын отканнар. Бу вакыйга турында «Арча хәбәрләре» газетасы мөхәррире Исрафил Насыйбуллин шулхәтле хисләнеп сөйләде, әйтерсең лә Арчада хоккей буенча дөнья чемпионаты узган. Илле биш хуҗалыклы авыл бит ул Субаш Аты, зур-зур авылларның, Арчаның үзенең командаларын пыр туздырды, ди. Мондый ярышларның инде ничә ел баруы, аларда һәр ел саен ничә команда, ничә хоккейчы катнашуы турында кызыксына башлаган идем, Исрафил: «Илһам Шакировтан сора!» – диде. Баштарак аптырап калдым, билгеле, егет шаярта, дип уйладым. Арчадагы хоккей ярышларында Илһам Шакировның ни катнашы бар инде?! Шуннан соң гына башка сукты, бит безнең якта Шакиров фамилияле гаиләдә ир бала туса, аңа «Илһам» дигән исем кушу гадәте бар. Ә Арчада ике Илһам Шакиров үзләренең тормышын спорт белән бәйләгәннәр. Берсе – минем авылдаш, Кави абый белән Хәерниса апа малае. Арчада «Татавтодор» оешмасында эшли һәм шул ук вакытта Субаш Аты хоккей командасының тренеры да. Бу эш буенча махсус белеме дә юк. Сораштыра башлагач: «Үзең беләсең, Риман абый, мин бит – кечкенәдән хоккей уйнап үскән малай», – дип куйды. Оятыма каршы, белмим шул, Илһам энем, сезнең район башлыгы кубогын алуыгызны ишеткәч, команда тупларга каян егетләр тапканнар икән дип тә уйлап куйган идем әле.

Илһам Шакиров миңа, бармак бөгә-бөгә дигәндәй, кем малайларының хоккей уйнаганын санап чыкты. Бар икән бит Субаш Атыда гаярь егетләр, хәтта безнең күршедә дә өч хоккейчы бар икән.

Илһам Шакировның уллары Илфар белән Илфат бик оста һөҗүмчеләр икән, финалда нәкъ менә алар керткән алкалар командага җиңү китергән. Гаилә белән «шар сугучы»лар тагын бар икән әле туган авылымда. Үзем шатланам, үзем: «Нәрсә булган Субаш Атыга?» – дип куям.

Икенче Илһам Шакиров – Арчаның «Боз сарае» директоры мине тагын бер кат гаҗәпләндереп куйды. «Ике көн барган финал ярышларын көн саен ким дигәндә 600–700 кеше карады, алар арасында сезнең авылныкылар бик күп иде. Соңгы уен тәмамлангач, җиңүче билгеле булгач, бөтен боз өсте Субаш Аты халкы белән тулды. Сезнең авылда шулхәтле кеше яшидер дип уйламаган идем. Кечкенә балаларын күтәреп килүчеләргә хәтле күзгә чалынды», – дигән иде ул. Моңа бик үк ышанмас та идем, бер авылдашым Илдар Исмәгыйлев: «Караклар килсә, барлык өйләрне чистартып китә алырлар иде, бөтен авыл шушында бит», – дип сөйләнгәләп йөргән. Әлбәттә, бераз шаярткандыр да Илдар, тик менә Субаш Атыга спорт җене кагылуы, авылдашларымның хоккейны культ дәрәҗәсенә күтәрүләре – хак. Авылдашым Илһам Шакировтан халыкның Арчага нинди транспорт белән килүләрен сораштым. «Автобус ялладыгыз мәллә?» – дидем. «Үз машиналарына төялеп килделәр», – ди Илһам. Егетләр хоккейчы формаларына хәтле үзләре сатып алалар икән.

Җанатарларның берсе, 68 яшьлек авылдашым Рәшидә Хәбибрахманова: «Бу җиңү кеп-кечкенә Субаш Аты өчен олимпиадада җиңүгә тиң!» – дип мактанып сөйләп йөргән ди.

Авылның яшәешен сыерлар саны, ит, сөт, май җитештерү белән генә күзаллау дөрес түгел, болар – авыл тормышының бер генә ягы. Татар тормышка чат ябышып яшәргә, нинди генә кыенлыклар килсә дә, аларны җиңеп чыгарга, үз тормышын үзе матурларга, төрләндерергә, иң матур гадәтләрне саклап яшәргә өйрәнгән халык, дип уйлыйм.

Без балачактагы шар сугу да онытылмаган, алай гына да түгел, профессиональ спортка әйләнеп бара. Киләчәктә, ил спорты данын яклаучылар арасында Субаш Аты егетләре дә күренмәгәе әле дип тә өметләнәм әле мин. Ә нәрсә, спорт дөньясында татар исемнәре җитәрлек бит!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

arskmedia.ru

Вакыйга

«КАДЕРЕН БЕЛЕП БЕТЕРМӘДЕК»

ТҮБӘН БӘРӘСКӘДӘ РӘФКАТЬ БИКЧӘНТӘЕВ ИСЕМЕ МӘҢГЕЛӘШТЕРЕЛДЕ

Әтнә районы үзенең асыл улын хәтерендә яңартты. Түбән Бәрәскә авылы мәдәният йортына ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле артист һәм режиссер Рәфкать Бикчәнтәев исеме бирелде. Тантаналы чарада «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

tatar-inform.ru

– Бүген безнең гаилә өчен генә түгел, мәдәниятебез, милләтебез өчен зур вакыйга. Без аңа күңелебез белән күптән әзер идек. Әтинең тууына 100 ел булу уңаеннан бу эшкә керештек. Бик тиз эшләнелде. Моның өчен авыл, район җитәкчелегенә бик зур рәхмәт. Бүген Коръән ашы уздырдык. Чаллыдан, Мәскәүдән туганнар кайтты. Бикчәнтәев нәселе ул бөтен дөньяга таралган. Америкада да яшиләр, Бәрәскәдә дә туганнарыбыз бар әле. Бүген – туганнар җыелган көн, – диде Рәфкать Бикчәнтәевнең улы, Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев. – Кызганыч, әтине балачактан гына хәтерлим. Күбрәк сөйләүләре буенча беләм. Әлбәттә, аның турында бик күп «легенда»лар сөйлиләр. Ул кабатланмас шәхес булган. Марсель Сәлимҗанов миңа әти турында бер нәрсә генә әйтте. «Андый актер бүтән юк», – диде. Минем өчен бу – бик зур бәя.

Район башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Каюмов Әтнә ягының татар дөньясына бөек шәхесләр бирүен билгеләп узды.

– Бу – безнең Бәрәскә өчен генә түгел, районыбыз, республикабыз өчен тарихи вакыйга. Шәхесләрнең исемен, хезмәтләрен мәңгеләштерү – иң зур бурычларның берсе. Бәрәскәдә һәрбер тыкрык, һәрбер йортның ниндидер тарихы, танылган шәхесе бар. Рәфкать абый татар халкына хезмәт иткән кебек, аның исемен йөрткән мәдәният йорты да районыбыз, республикабыз халкына хезмәт итәр, дип ышанам, – диде Айрат Каюмов.

Ленин исемендәге күмәк хуҗалык җитәкчесе Илгиз Хәйруллин легендар шәхес турында:

– Сәнгать өлкәсендә безнең авылдан чыккан шәхесләр күп. Рәфкать Бикчәнтәев – алар арасында иң якты йолдыз. Кызганыч, үзе яшәгән вакытта кадерен белеп бетермәдек, – дип сөйләде. – Әмма еллар узган саен, аның шәхесе ачыла, бәһасе күтәрелә бара, аның бөеклеген, даһилыгын, никадәр көчле артист һәм режиссер булуын аңлыйбыз. Әлбәттә, бу юнәлештә хатыны Наилә Гәрәева, улы Фәрит бик күп хезмәт куйды. Наилә ханым Бәрәскәдә үз кеше иде, аны авылда бөтен кеше яратты. Ул бу көнне шулкадәр көтте, планнар корды, сценарийларын төзеп калдырды. Кызганыч, күрә алмады. Фәритне дә каны авылга тарта. Геннар шулкадәр көчле: Фәрит Рәфкатович, әтисенең эшен дәвам иттереп, зур дәрәҗәдәге көчле режиссер булды.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Аида Фатыйхова мәдәният йортына Рәфкать Бикчәнтәев исеме бирелүнең җаваплылыкны арттыруын әйтте.

– Рәфкать абый киңкырлы шәхес булган. Мәдәният йортына аның исеме бирелү – бик зур горурлык та, җаваплылык та. Киләчәктә Бәрәскә халык театры Рәфкать абыйның исемен акларлык, аның рухы шат булырлык итеп эшләр дип ышанам, – диде җирлек башлыгы. – Китаплардан укып, Рәфкать абыйның шаян, җор телле булганын, пөхтә киенгәнен, кызык-мызык сөйләп, үзенә җәлеп иткәнен беләбез. Рәфкать абыйның геннары йогынтысын мин Фәрит абыйда күрәм. Алар аны чын ир-егет итеп тәрбияләгәннәр, ул – туры сүзле, гадел һәм искиткеч талантлы шәхес.

Бабасының исемен мәңгеләштерүгә бәйле хис-кичерешләре белән Рәфкать Бикчәнтәевнең оныгы Йосыф Бикчәнтәев тә уртаклашты.

– Бүгенге вакыйга күңелгә нык тәэсир итә. Бүтәнчә була да алмый. Вакыт узганнан соң да шәхес турында хәтерне саклау, кадерен белү мөһим. Әтнә ягы, Бәрәскә мине үзенә бик тарта. Җәй көннәрендә үзем генә дә, әти-әни белән дә авылга кайтабыз. Монда ешрак буласы килә, балачак хатирәләре искә төшә, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Зөһрә САДЫЙКОВА

Авыл рухы

СӨННӘТЧЕ БАБАЙ АВЫЛЫ

Элеккеге елларда Татарстанда сөннәтче бабайлары, кендек әбиләре белән дан казанган авыллар булган. Мондый үтә дә нәзберек, җаваплы йоланы бик сирәкләргә генә ышанып тапшырганнар. Әлмәт районының Бишмунча авылы да күрше-тирә салаларда яшәүчеләрнең хәтерендә әнә шундый иманлы, динле авыл буларак сакланган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

XX гасыр башларында киң таралган күренеш – сөннәтчелек турында күбрәк белергә теләп, без мәчеткә юл тоттык. Ниятебез авыл агайларын өйлә намазыннан соң тотып алып, сөйләтү иде.

– Элек безнең авыл бик зур, көчле һәм данлыклы булган, – дип каршы алды алар безне. – Бөек Ватан сугышына гына да Бишмунчадан 527 кеше чакырылган. Никадәр өрлек кебек ир-егетләр бер авылдан чыгып китсен әле! Аларның яртысыннан күбрәге яу кырында ятып калган. Ут эченнән исән чыкканнары да бүген якты дөньяда юк инде.

Аксакаллар арасында Юныйс Гиниятуллин да булыр, дип алдан ук кисәтеп куйганнар иде. Авыл халкы аның бабасының да, әтисенең дә данлыклы сөннәтчеләр булуын әйтеп куйды. Шуңа күрә алга таба сөйләшүебезне аның белән дәвам иттек.

– Мин Бишмунчада гомер иттем, әти-әниемнең төпчек малае. Туган йортым урнашкан урам зур, матур иде. Һәм биредә чыннан да бик күп сөннәтче бабайлар яши иде, – диде ул. – Шуңа күрә аны «сөннәтчеләр тыкрыгы» дип йөрткәннәр. Мин ул бабайларның берничәсен бик яхшы хәтерлим әле. Әтиебез дә өлкән яшенә кадәр малайларны сөннәтләү бурычын башкарды. Бик иманлы, гадел, чиста-пөхтә, тәртипле кеше иде. Чисталык буенча без – балаларга да таләпләр катгый булды. Ул чор кешеләре туып, үзләрен белә башлаганнан бирле Аллаһы Тәгаләгә ышана иде бит. Әти дә үз гомерендә бер генә тапкыр да тәмәке тартып, аракы эчеп карамаган кеше иде. 83 яшенә кадәр матур итеп яшәде. 96 яшендә мәрхүм булган әбием дә бер намазын да калдырмады.

Авыл халкы сүзләренчә, Бишмунчаның сөннәтче ир-атларының даны бөтен республика, күрше-тирә төбәкләргә таралган булган. Алар җәяүләп тә, поездга утырып барып та, авыллар буйлап йөреп, яшь малайларга сөннәт йоласын башкарган, шушы хезмәт белән көн иткән, гаиләләрен туендырган.

– Мин тумышым белән Әтнә районыннан. Безнең якларда сөннәтче бабайлар булганын хәтерләмим. Каяндыр килеп йөрүләрен генә беләм. «Авылда чит кешеләр күренә, кемнәр килгән?» – дип сорагач, «Сөннәтчеләр килгән», – дип җаваплыйлар иде, – дип искә алды яшьлек хатирәләрен Габделәхәт Фәттахов.

Ни хикмәт, 1921–1922 еллардагы бик көчле ачлык Бишмунчаны урап узган. Биредә яңгыр яуганлыктан, халык ашлыкка, икмәккә тилмермәгән. Монда яшәүчеләр исә моны авылның иманлы, динле, сөннәт гамәлен башкаручылар күп булуы белән аңлата.

– Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәрендәге күп күренешләр минем өчен дә бик якын, таныш. Минем әтиемнең дә бик кадерләп кенә тота торган пәкесе бар иде. Ул аны бик пөхтә итеп, саклап, кадерләп кенә тотты. Сөннәтләнгән балалар арасында үлем-китемнәр, авыр очраклар турында берни дә хәтерләмим. Ул турыда сөйләүче булмады безгә. Ләкин андый очраклар турында башкалардан ишеткәләргә туры килде. Аннан соң: «Сөннәтләгән йөзенче бала үләргә тиеш булган икән», – дигән имеш-мимешләр дә колакка кереп калган. Аның ни дәрәҗәдә дөрес булуын хәзер әйтеп булмый инде, – диде Юныйс ага.

Сөннәтчеләрнең янчыгында күз карасыдай саклый торган тагын бер әйберләре булган: яра тизрәк төзәлсен өчен алар үзләре белән агачның череген йөртә торган булганнар. Соңрак кына халык дәвасын стрептоцидка алыштырганнар.

– Минем энемне Ибраһим бабай сөннәткә утырткан иде. Аның янчыгыннан черек алып сипкәне әле дә күз алдында. Хәзер малайларын кызганып, үскәчрәк кенә сөннәтләүчеләр дә бар. Тик безнең бабайлар бу йола никадәр тизрәк башкарылса, шуның кадәр яхшырак, дип әйтә иде. Шуңа күрә алар бу эшне озакка сузмыйча, сабый тугач, җиде көн узуга ук башкарды. Аларны малай туып, өйгә кайтуга ук чакырталар иде. Махсус догасын укып, бик сак кына башкарыла торган матур гадәт иде ул, – диде Илдар Лотфуллин.

Әлеге һөнәрне нәселдән нәселгә тапшыру да Бишмунча сөннәтчеләренең бер күркәм бурычы булып саналган. Авыл агайлары сүзләренчә, сөннәтче бабайлар 1980 нче еллар башында да булган әле.

– Мин укыган елларда да авылда 7–8 бабай бар иде әле. Билгеле, аннан соң бу эшләр махсус белеме булган табиблар кулына күчте. Без балачак чорда бала-чагасы да күп иде бит аның. Икешәр-өчәр класс укыдык. Ә хәзер, бала юк, дип мәктәп ишекләренә йозак эләләр. Авылда мәктәп бетә икән, тел бетә, тел бетсә, милләт бетә. Менә шунысы яман, – ди Юныйс Гиниятуллин.

Заманында бик дини, иманлы авыл буларак даны таралган Бишмунча бүген нинди хәлдә соң? Әлеге сорауны биргәч, авыл агайлары елмаеп, «авыл таралып бара шул инде, кызым» дип кенә куйдылар. Шулай да авыл уртасындагы күркәм мәчетләре җомга, бәйрәм намазларында халык белән шыгрым тулы була икән. Ә гадәти көннәрдә мәчеткә сукмак салучылар унга да тулмый.

Ватан хакы

Без бергә көчле

Махсус хәрби операциядәге егетләргә туган яктан нинди генә күчтәнәч китми. Газизләренә якыннары иң тәмлесен ашатырга, иң җылысын кидерергә тели. Аларга Ватанны саклар өчен барлык мөмкинлекләр тусын дип, кулдан килгәнне башкаралар. Егетләргә ярдәм итмәгән бер генә авыл, бер генә йорт та калмагандыр. Һәркем үз өлешен кертергә тырыша.

Апастан шушы көннәрдә махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә гуманитар ярдәм төягән машиналар кузгалды. Егетләр янына район башлыгы Айрат Җиһаншин да киткән. Апас егетләре махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен 4 мич-буржуйка ясап тапшырган. Хатын-кызлар өй токмачы әзерләгән, яралыларны ташу өчен махсус носилкалар теккәннәр.

Кукмаралылар да читтә калмый. Волонтерлар Алсу Шәйхетдинова һәм Гүзәл Аввакумова социаль челтәрләрдә махсус ярдәмләшү төркеме төзегән. Биредә республиканың башка районнарыннан, Киров, Кизнер, Сахалин һәм башка өлкәләрдән дә, егетләргә дип, акча күчерүчеләр бар икән. Район халкы да теләп кушыла.

Кукмарада егетләр өчен кирәк-ярак тегүче цех та бар. Анда 40тан артык тегүче эшли. Алар СВОга балаклава, маскхалатлар, термо киемнәр җибәргән. Яңа Комар авылыннан эретеп ябыштыручы Илһам Сәхәбиев, Кукмарадан Артур Хәйбуллин ярдәме белән 40 данә мич-шәм һәм 55тән артык мич-буржуйка җибәрелгән.

Актаныш егетләренә туган яктан броньлы «УАЗ – Патриот» автомобилен тапшырганнар. Аларга якыннарыннан исемле посылкалар, күчтәнәчләр дә барып җиткән инде.

Зәй районының Шыкмай авылыннан Назыйм Минһаҗев махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә дисбеләр әзерләп җибәргән. Ул Зәйдә маскировка челтәрләре үрүче хатын-кызлар янында да еш була. Әлеге игелекле затларга һәрвакыт баллы күчтәнәчләрен дә алып килә, челтәр үрү өчен материаллар алуга акчалата да ярдәм итә. Махсус хәрби операция зонасына җибәрү өчен, авылда окоп шәмнәре ясау эшен дә оештырган.

– Кичтән авылдашларга, махсус хәрби операциядә катнашучы егетләребезгә окоп шәмнәре ясарга алыныйк әле, дип мөрәҗәгать иткән идем. Ә икенче көнне иртәнге сәгать 8дә клубка шәм ясарга җыелдык та инде. Клуб салкын булса да, ясаган шәмнәргә карап күңелләребез җылына, – ди Назыйм абый.

Казанның Константиновка бистәсендә яшәүчеләр дә читтә калмый. Мәдәният йорты директоры Наталья Фәритова әйтүенчә, егетләр туган як җылысын тагын да ныграк тойсын өчен, алар тәмле чәйләр җибәрәләр. Чәй янына баллы ризыклар да әзерләнә.

– Егетләр ни сорый, шуны җыеп бирергә тырышабыз. Арада, яраланып, госпитальләрдә ятучылар да бар бит. Алар өчен дә кирәк-ярак әзерләдек. Шәмнәр дә ясадык. Үз куллары белән картиналар ясап җибәрүчеләр дә бар. Аеруча мәдәният йорты каршында урнашкан «Жизнелюб» клубына йөрүчеләр актив. Алар нинди генә эш булмасын, бик теләп башкара, – ди ул. – Шунысы сөендерә: әзерләгән күчтәнәчләр егетләргә барып җитә. Алар безгә рәхмәт әйтеп, видеохәбәрләр юллыйлар. Бер генә теләк – илебезне саклаган егетләребез исән-имин булсын. Тизрәк дөньялар тынычлансын иде.

Мамадыш районының Югары Сон авылы кызлары исә, егетләргә дип, пилмән бөккән.

– Иң тәмлесен ашатасы килә бит. Чәкчәген дә пешерәбез. Оекбашын да бәйлибез. Алар үзләре зарлана белми. Әмма без аларга җиңел түгел икәнен беләбез, – ди мәдәният йорты директоры Гөлсинә Гарипова.

...Шушы көннәрдә ике атналык ялга кайткан гаилә дустыбызны тагын махсус хәрби операциягә озаттык. «Без бергә көчле. Үзем монда булсам да, күңелем белән егетләр янында мин. Ашарга җитәрлек, киемебез бар», – ди Сабадан Илнар Хаев. Сүз ияреп, тычканнар хакында сораштым. Татарстаннан килгән мәчеләрдә бар өмет, ди. Шул песиләргә дә тәмле күчтәнәчләр алып китә әле.

– Әти-әни безне бердәм булырга өйрәтте. Бер телем икмәкне дә бүлешеп ашаган кешеләр без. Ә инде СВОда яңадан шушы хисләр барлыкка килде. Тормышка караш бөтенләй үзгәрде. Монда ялга кайткач та, күңел тыныч түгел. Бер егетебез минага баскан, икенчеләр алгы сызыкта, өченчесе, мин килгәч, ялга кайтачак. Илебез тыныч булсын өчен, без анда кирәк, – диде ул. – Ят җирләрдә, басу-кырларда ятсак та, тылдагылар безне ташламый. Һәр кешегә, аеруча балаларга матур хатлары өчен мең рәхмәт. Җиңү белән кайту язсын безгә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯШЬ ГАЛИМ АЙЗИРӘК САДЫЙКОВ:

«КҮСЕНЕҢ ДӘ ФАЙДАСЫ БАР»

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

Күсе һәм кеше йөрәге. Казан федераль университетындагы Кеше сәламәтлеген саклау кафедрасының өлкән мөгаллиме Айзирәк Садыйков ике арадагы аерманы өйрәнә. Бу ни өчен кирәк? Яшь галимнән тикшеренү нәтиҗәләре турында сораштык.

Айзирәк – Чистай районы Мөслим авылы егете. Кечкенәдән туган авылының табигатенә сокланып үскән. Биология белән кызыксынуы шул еллардан ук килә. 2013 елда Мөслим мәктәбен алтын медальгә тәмамлап, КФУга укырга кергән. Университетта укыганда, фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнә башлый ул. Хәзерге вакытта галим-физиолог Нәфисә Зыятдинова җитәкчелегендә аспирантурада укый, кандидатлык диссертациясе яза. Диплом алгач, яшь белгеч Казанның 2 нче татар гимназиясенә эшкә урнаша. Белем биреп кенә калмый, укучыларда табигатькә карата хөрмәт уята, сакчыл караш булдырырга тырыша. Тик фәнгә күбрәк вакыт калсын өчен, үзе укыган университетта укытуны кулайрак саный.

Без күселәрдән җирәнеп, борын чөерсәк, ә монда башкача. Белгечләр өчен алар кадерле җан иясе кебек. Тәҗрибә үткәрүчеләр әхлак дигән нәрсәне онытмый. Әлбәттә, курку хисе дә юк. Башкача булганда, тәҗрибәнең уңышлы чыгасына өметләнергә дә кирәкми.

Күселәр идән астында түгел, университет вивариенда яши. Аларның саны йөзләгән. Шартлар яхшы. Махсус азык, асларына йомычка һәм башка кирәк-яракны университет сатып ала. Барлык тикшеренүләр дә университетның Кеше сәламәтлеген саклау кафедрасы лабораторияләрендә башкарыла. Заманча җиһазлар ярдәмендә йөрәк эшчәнлегенең дистәләгән күрсәткече яздырыла һәм анализлана. Әлеге тикшеренү юнәлешен кафедра мөдире, республиканың атказанган фән эшлеклесе, профессор Тимур Зефиров җитәкли.

– Мин йөрәк эшчәнлеген көйләү механизмнарын өйрәнәм. Йөрәк-кан әйләнеше системасы эчке һәм тышкы тирәлек йогынтысын бик тиз тоя. Тормышта киң таралган тискәре факторлар беренче булып әлеге системага тәэсир итә, – ди 28 яшьлек Айзирәк.

Тәҗрибәдә ак токымсыз күселәрне куллануары да юкка түгел. Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, имезүче хайван буларак, йөрәк төзелеше һәм эшчәнлеге кешенекенә охшаган. Икенчедән, тиз арада күпсанлы токым алырга мөмкин. Шулай ук күселәрнең үз-үзләрен тотышы, генетикасы төрле авыруларны, яшәеш, картаю үзенчәлекләрен өйрәнү мөмкинлеге бирә. Кеше сәламәтлегенә начар йогынты ясаучы, әйтик, аз хәрәкәтләнү, агулы газлар яки башка тәэсирләрнең күселәргә йогынтысын да ачыклыйлар.

Яшь белгеч аңлатуынча, йөрәк, кан тамырлары авырулары яшьләрдә дә, өлкәннәрдә дә еш күзәтелә. Ләкин йөрәк төрле яшьтә төрлечә эшли. Димәк, профилактика да, авыруларны дәвалау да бер үк була алмый. Шуңа күрә тәҗрибәләрнең төрле этабында төрле яшьтәге күселәрне кулланалар. Молекуляр механизмнарны ачыклау, күзәнәктәге процессларны өйрәнү, органның эшчәнлеген анализлау өчен дә кирәк бу. Гадирәк итеп әйткәндә, теге яки бу препаратларның йөрәк эшчәнлегенә йогынтысын ачыклыйлар.

– Һәрбер кечкенә генә ачыш – зур максатка бер адым. Тикшеренү өлкәсенә юл кечкенәдән салына. Шушы яшьтән кызыксынуны үстергәндә, баланы мәктәптә үк фәнгә юнәлтеп була. Мин укытучыларыма рәхмәтле. Яшәеш фәннең юнәлешен билгеләсә, фән кешелекнең киләчәген яктырта, – ди яшь галим.

Сәрия МИФТАХОВА

Рәсми документлар

ЦЕНТРАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПОСТАНОВЛЕНИЕ

29 февраля 2024 г. г. Казань № 40/297

О передаче вакантного мандата депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шиминой Нине Константиновне

В связи с досрочным прекращением полномочий депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Тыгина Александра Васильевича, избранного в составе республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», в соответствии с частями 1.1 и 1.2 статьи 103 Избирательного кодекса Республики Татарстан, учитывая выписку из протокола заседания Президиума Регионального политического совета Татарстанского регионального отделения Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ» от 20 февраля 2024 года с решением предложить Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан кандидатуру зарегистрированного кандидата в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан Шиминой Нины Константиновны (порядковый номер в республиканском списке кандидатов 55) для замещения вакантного депутатского мандата, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан **постановляет**:

1. Передать вакантный мандат депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шиминой Нине Константиновне (порядковый номер в республиканском списке кандидатов 55).

2. Опубликовать настоящее постановление в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан».

Председатель
Центральной избирательной комиссии
Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Исполняющий обязанности секретаря
Центральной избирательной комиссии
Республики Татарстан Р.Р. Валиуллова

ЦЕНТРАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПОСТАНОВЛЕНИЕ

29 февраля 2024 г. г. Казань № 40/298

О регистрации депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Шиминой Нины Константиновны

На основании постановления Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан от 29 февраля 2024 года № 40/297 «О передаче вакантного мандата депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шиминой Нине Константиновне», в соответствии с частью 4 статьи 100, пунктом 7 части 5 статьи 103 Избирательного кодекса Республики Татарстан Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан **постановляет**:

1. Зарегистрировать депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Шимину Нину Константиновну.

2. Выдать зарегистрированному депутату Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва удостоверение об избрании.

3. Исключить зарегистрированного кандидата в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Тыгина Александра Васильевича (порядковый номер в республиканском списке кандидатов 27) из допущенного к распределению мандатов депутатов Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ».

4. Опубликовать настоящее постановление в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан».

Председатель
Центральной избирательной комиссии
Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Исполняющий обязанности секретаря
Центральной избирательной комиссии
Республики Татарстан Р.Р. Валиуллова

УКУЧЫ СҮЗЕ

Беренче театр

Зәй районының Карман авылы үзешчәннәре Түбән Каманың Түбән Чаллы авылында хәйрия чарасы үткәрделәр. Шуннан кергән 19 мең сум акчага махсус хәрби операциядә катнашучыларга шәм ясау һәм челтәр үрүгә кирәкле материаллар алачаклар.

Карманлылар Галиәсгар Камалның «Беренче театр» спектаклен сәхнәләштерделәр. Образлар шулкадәр дөрес ачылган, сәхнә гади генә булса да, заманасына туры китереп бизәлгән, киемнәре зәвыклы, рольләрен бөтен нечкәлекләренә туры китереп уйныйлар.

Спектакль беткәч, концерт та булды. Бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй, 70ен тутырган Котдүс абый Шакиров та, сәхнәне селкетеп, биеп күрсәтте. Түбән Чаллыга багышлап язган шигыремне, җиренә җиткереп, апам Фирдания Ханнанова укыды.

Түбән Чаллыда үткән чараның идеясен абыем Әлфрит Шәйхелисламов әйткән иде. Калганнарыбыз, бик теләп, бу фикергә кушылды. Бу авыл да юкка гына сайланмаган. Әле дә минем балачакның сере сакланган зәңгәр йорт бар анда! Ул – әнием Нурдидә Шәйхелисламованың туган авылы.

Үзешчәннәрнең яшь арасы 50дән алып 70кә кадәр. Барысы да диярлек – туган авылларына әйләнеп кайткан, олыгаеп килгән авылдашларыбыз тормышына яңа сулыш өргән шәһәр пенсионерлары. Һиндидер бер талпыну белән дәррәү кайтып төште алар Карманга. Туган нигезләрен яңартып, тавык-чебеш, кәҗә-сарык асрап көн күрәләр.

Эш тәмамлангач, авыл клубында җыелырга сәбәбе чыгып кына тора. Я бер бәйрәмгә, я икенчесенә әзерләнергә кирәк. Ике ел буена Карман кешеләре, кичләрен клубта җыелып, махсус операциядә катнашучылар өчен шәмнәр ясыйлар, челтәр үрәләр. Бүгенгә 2000нән артык шәм коелган, 20ләп челтәр үргәннәр. Аларның берсе Гафифә ролен башкарган Айсылу Камалиеваның энесенә шәхсән атап җибәрелде. Челтәрнең үз иясенә барып ирешүе турында хәбәр килде.

Күптән түгел Әлфрит Шәйхелисламов башлангычы белән авылдан чыккан кешеләрне барлап, алардан да 26 мең сум акчалата ярдәм җыйдылар. Хәзер шул акчага 300 кг парафин кайтарттып, һәр көнне шәм коялар. Түбән Чаллы авылы халкы да бу яктан искиткеч ярдәмчел булып чыкты.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА. Казан

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кыялмассың

Чатнама кыш суыттымы
Кинәт кенә араларны?
Күзең чагып ялган кояш
Сине миннән аралады.

Өермәләр адаштырган,
Саташтырган уйларыңны...
Бергә яккан учакларны
Сүнәр диеп уйладыңмы?

Язлар булып кайтырмын мин
Иләсләнгән күңеләңә.
Ышандыра алмас беркем
Тик минеке түгеләңә.

Икәү таткан бәхет тәмен
Онытырга кыялмассың...
Безнең сөю кыйссабызга
Соң ноктаны куялмассың.
Кыялмассың...

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

ЧҮПРӘЛЕДӘН – БЕРДӘНБЕР

Чүпрәле урта мәктәбе – республикабызда бай тарихлы мәктәпләрнең берсе. Биредә фән докторлары, күпләгән профессорлар, доцентлар, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, атказанган агрономнар, табиблар, инженерлар, укытучылар, хезмәт җитәкчеләре һәм алдынгылар, космосны үстерүче академик Руханил Гафуров, Россия Герое Газинур Хәйруллин һәм башкалар укып чыккан.

Бүген мәктәптә талантлы, югары белемле, мәрхәмәтле, укучыларга йөрәк җылысын бирүче укытучылар коллективы тупланган. Бу – әлбәттә, мәктәп директоры Лилия Насыйбуллина куйган зур тырышлык нәтиҗәсе. Һәр елны мәктәпне ун һәм аннан да артыграк бала алтын медальгә тәмамлап чыга.

Укытучылар коллективында районда гына түгел, республикабызга даны таралган мактаулы татар теле һәм әдәбияты укытучысы Минзифа Таҗетдинова да бар. Ул шушы мәктәптә инде өч дистә елдан артык балаларга туган телне өйрәтә.

Минзифа ханым районыбызның Татар Бизнәсе авылында туа. Сигез сыйныфны тәмамлагач, Арча педагогия училищесында укый. Аннан Казан дәүләт университетының татар теле, тарих һәм Көнчыгыш телләр факультетында белем ала. Иске Чүпрәле урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбият укытучысы булып эшкә урнаша. Даими рәвештә белемен күтәрә, күпләгән курсларда укый, аспирантура баскычларын үтә, Һади Такташ иҗатына әрняа анализ ясый. Фәнни-тикшеренү хезмәтен укыту эшчәнлегендә файдалана. Һөнәри бәйгеләрдә катнаша. «Туган якны өйрәнү» түгәрәге оештырып, милли мәдәниятне, нәсел җепләрен, туган төбәкнең тарихын өйрәнүгә зур игътибар бирә.

Буләкләре санап бетергесез. «2000 елның иң яхшы татар теле укытучысы» республика конкурсында югары күрсәткечләре өчен Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. «Мәгариф» илкүләм проектын

тормышка ашыру кысасында үткәрелгән «Россия Федерациясенең иң яхшы укытучылары» конкурсында җиңеп чыгып, Президент грантына ия була һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Мәскәүдә Кремль сараенда үткәрелгән җыенда районыбыздан делегат булып катнаша. Район һәм республика җитәкчеләреннән һәм республика, Россия министрлыгыннан, ронодан алган Мактау грамоталары, дипломнары иллдән артык.

Тормыш иптәше Шамил Таҗетдинов та – шул ук мәктәптә укытучы. Республика җитәкчеләре, Чүпрәлегә килгәч, мәктәпкә керми китмиләр. Беренче булып Шамил Хасиятулла улының технология һәм физика дәресләренә кереп, хәйран калып чыгалар. Укучы балаларның дәрестә һәм түгәрәктә кызыксынып укуларына зур бәя биреп, мәгариф өлкәсендә зур эшләр башкаруы өчен рәхмәтләрен әйтеп китәләр.

Кызлары Гүзәл белән әнәү эш тәҗрибәләрен уртаклашып, «Иҗади эзләнүләр юлында» исемле китап бастырып чыгардылар. Бу җыентыкка алдынгы педагогик тәҗрибә урнаштырылган, шулай ук сәләтле укучылар белән эшләү алымнары, укучыларның иҗади хезмәтләре тупланган. Гаилә өчен ул бик тә кадерле, ә укытучылар өчен – файдалы кулланма. Таҗетдиновлар икесе дә – районыбызның атаклы язучы-фронтовигы Зәки Нури премиясе лауреатлары. Икесе дә җәмәгать эшлеклеләре. Мәдәнияте йортында үткәрелгән һәрбер кичәдә һәм концертта чыгыш ясарга да өлгерәләр. Бүген тарихи багланышлар белгече булган кызлары Гүзәл республика күләмендә татар телен үстерүдә үзеннән зур өлеш кертә. Ә уллары Данияр – татар теле буенча республика күләмендә олимпиадаларда җиңүче, нәфис сүз остасы, баянда татар халкының милли көйләрен бик оста уйнаучы һәм җырчы да.

Күптән түгел Рәисебез Рөстәм Миңнеханов Кремльдә, үрнәк гаиләләрне җыеп, зур бәйрәм үткәрде. Анда Чүпрәле районыннан бердәнбер гаилә – Таҗетдиновлар чакырылды.

Әмир САБИРҖАНОВ. Чүпрәле

Кырык беренче ел балалары



Өч көн рәттән Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары»н укыдым. Бер төндә укып бетерәм дә икенче, өченче тәннәрдә кабат кулыма алам. Укыган саен укыйсы, әсәр геройлары белән аралашасы килә. Моннан 55 ел элек язылган булса да, ул бүгенге вазгыятьне чагылдыра. Чоры, кешеләре башка, әмма уртаклык бар!

Шул рәвешле мин Балтач районының Кенә мәктәбендә республика күләмендәге ачык әхлак дәресендә катнашырга әзерләндем. 105 еллык бай тарихы булган бу мәктәп районда беренчеләрдән булып оешкан. Әнием Миңлегөл да сугыш чорында шунда укыткан. Ул гел: «Кенә мәктәбе укучылары тырыш, гыйлемгә омтылучан, чиста-пөхтә йөриләр иде», – дип искә ала иде. Мин дә Карадуганда Кенә балаларын укытканда, моның шулай икәнлегенә инандым.

Әхлак дәресе

Затлы милли киемнәрдән курайчы кызлар уйнаган «Туган тел» җыры мәктәпкә генә сыешмыйча, бөтен авылга яңгырый. Капкадан кичәнең мәртәбәле кунаклары – кырык беренче ел балалары – филология фәннәре докторлары, профессорлар Хатыйп Миңнегулов белән Фоат Галимуллин керә. Мөхәммәт Мәһдиевнең иңгә-иң куеп эшләгән хезмәттәшләре...

Әхлак дәресләренә юл тотабыз. Темасы да актуаль – «Белем бирүнең фәзыйләтләре». Белем – бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы, диләр. Тик югары баскычка күтәрелү өчен тырышлык, үҗәтлек һәм хәерле гыйлем алу кирәк. Дини һәм дөньяви гыйлемне тигез күреп өйрәнеп, Аллаһ кушканнарны үтәп, ул тыйганнардан тыелып, барына шөкер кылып, киләчәккә өмет белән яшәсәк, дәрәҗә баскычыннан күтәрелә алырбыз. «Укыган кеше картаймый, – ди укытучы, – чөнки аның күңеле яшь кала».

Укучылар фән, гыйлем, галим тамырлары кергән кеше исемнәре әйтә. «Исем кеше язмышына йогынты ясый. Шуңа балага матур мәгънәле исем кушу кирәк», – дип нәтиҗә ясый апалары. Дәрестә вакыт кадерен белү турында сөйләштеләр, күңелле тәнәфес тә ясадылар.

Мизгелләр

Очрашуның иң дулкынландыргыч мизгелләре – олпат галимнәребез белән аралашу. Галим Хатыйп Миңнегуловка сугыш башланганда өч яшь тирәсе булса, Фоат Галимуллин күкрәк баласы булган.

Әсәрдә: «Менә коридорның бу почмагында Түбән Кенә малайлары. Барысы да чиста ыштырдан, яңа чабатадан. Менә зәңгәр сырма кигән Карадуган малайлары – һәммәсе кишер ашый», – дигән юллар бар.

Бер елны Мөхәммәт аганы классташлар очрашуына Кенәгә чакырлар. Ул бик теләп сабакташлары белән очраша. Кызганыч, алар да мәңгелек йортка күчкән. Бәхеткә, истәлекләр сакланган. Фәрит Закирҗанов үзе укыган мәктәбендә укыткан. Улы Раушан да – шушы мәктәп мөгаллиме. Ул әтисе истәлекләре белән таныштырды. 40 ел Кенәдә татар теле, әдәбияты укыткан Сәгыйрә апа (ул – мәктәп директоры Рамил Низамиевның әнисе) истәлекләрен онытыры Гүзәл сөйли.

Хатыйп ага – төрле телләрдә басылган 76 китапның авторы, биш баласы ишле гаиләдә «әти» сүзен әйтергә тилмереп үсә.

– Әнкәй Генсекретарь да, прокурор да, әни һәм әти дә булды. Бүгенге ирешкәннәребез белән без аналарга бурычлы, – ди ул. – Алга карап, тыныч тормышка өметләнеп яшик, мескенләнмик. Ач-ялангач ятимнәр җиңү таңына өметләнгән, беренче дә бауга менмәгән. Мәһдиев әсәрләре безгә юл күрсәтә, әсәр геройлары сабыр, максатчан, кешелекле, оптимист булырга өйрәтә.

Нәфис сүз остасы Фоат ага Галимуллин да гомере буе әтисен көтеп, аның кочагына сыенырга хыялланып яшәгән.

– Күп еллар Мөхәммәт Мәһдиев белән бер кафедрада, ярдәмләшеп, күркәм эшләр башкардык. Ул үзе дә бик әхлаклы кеше иде. Күкчәтауга Ибраһим Сәлаховның 80 яшьлек юбилеен үткәрергә баргач, 30–40 кеше җырлап урам әйләндек. Кызыл Яр авылы уянды, тәрәзәләрдә утлар кабынды, биредә яшәүче татарлар урамга йөгереп чыгып безгә кушылды. Мәһдиев бик оста сызгыра да иде, – дип истәлекләргә бирелде ул.

– Барлык чараларны укытучылар, китапханәчеләр, укучылар, әти-әни, дин әһелләре бергә эшләгәндә генә уңышка ирешеп була. Иң элек баланы да, үзебезне дә шөкер итәргә өйрәтик. Безнең максат – ана телебездә сөйләшә һәм китап укый торган укучылар, төп йорт килене булып төшәрлек кызлар, шөкер итеп яши белә торган булып тәрбияләү, – диде Җәлил хәзрәт Фазлыев, әхлак дәресләренә йомгак ясап.

Ә менә, ни өчен әхлак дәресләре башка төбәкләрдә эшләми икән, дигән сорау ачык калды.

Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА. Балтач, Югары Шубан

ЙОЛДЫЗЛЫК

Яңа елда мәдәният өлкәсенә булган сәяхәтемне 2024 елны Габдулла Тукай әдәби музеена барудан башладым. Бәхетемә, шул ук көнне «Музей йолдызлыгы» клубында очрашу да була икән.

Кышның зәмһәрир салкынында урамнан бу бинага кергәч, хезмәткәрләрнең ягымлы мөнәсәбәтен, кунакчыл мохитне, «Балалар бүлмәсе»ндә елмаеп утырган Шүрәле, озын чәчләрен тараткан Су анасын күргәч, үземне Тукай дөньясына, балачакка, туган йортка кайткан шикелле хис иттем. Күңелгә бәйрәмчә рәхәтлек инде. Талгын гына татар көйләре яңгырый. Шунда ук сувенирлар, китаплар сатыла торган киосктан балалар өчен шагыйрьнең «Шүрәле», «Күңелле сәхифәләр» китапларын, олылар өчен «Мәҗмугаи әсәрләре»н алырга була. Аякка кияр өчен тукымадан тегелгән бахилага кадәр балачак хатирәләрен яңартты.

Иртәрәк иде әле. Экскурсиядән чыккач, музейның фәнни хезмәткәре Әлфия ханым Шәриповадан клуб эшчәнлеге турында сорашттырдым.

– «Музей йолдызлыгы» клубы Габдулла Тукай әдәби музеенда узган ел гына эшли башлады әле, бүген анда 50 кеше клуб әһеле булып тора, – дип башлады ул сүзен. – Максатыбыз – Габдулла Тукайның, зыялыларның иҗатларын өйрәнү, иң мөһиме, бу турыда балаларыбызга, оныкларыбызга сөйләү. Клубка төрле буын вәкилләре йөри ала,

күбесенчә пенсия яшендәгеләр килә. Эшчәнлегебез кинкырлы. Музей экспозициясендә чагылыш тапкан төрле темаларны яктыртабыз. Фондны баетырга ярдәм итәбез. Язучылар, журналистлар, рәссамнар, диңгезчеләр берлекләре, «Ак калфак» һәм башка оешмалар белән күмәк чаралар эшлибез. Килачәктә Татар конгрессы һәм бөтен дөньяда яшәүче татар иҗтимагый оешмалары белән элемтәгә керү планы да бар. Бу очрашу-чараларыбызны, Тукай әйткәнчә, «утырышу» дип тә атыйбыз. Кызыклы язмышлы шәхесләр, үз эшенең остасы булган төрле хезмәт вәкилләре безнең җыелы очрашуларга бик теләп килә. Клуб эшен оештыруда башлап йөрүче Айсылу Гарифуллина, Фәния Габдрахманова зур рәхмәт. Күбебез – иҗат кешеләре: Галия апа Жылый, Эдуард абый нәфис сүз сөйли, Иршат абый гармунда уйный. Габдулла Тукайның күп шигырьләрен диярлек яттан белгән Фрадия апабыз да бар. Очрашуларда кунакларыбызга үз һөнәрләребезне дә күрсәтәбез.

2023 ел Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы иде. Шуңа узган ел үткәрелгән чараларда халыклар арасындагы дуслык темасы зур урын алып тора, клуб әһелләре арасында да төрле халык вәкилләре бар.

2024 ел илебездә Гаилә елы дип игълан итемде. Татар халкы элек-электән гаилә төшенчәсенә зур игътибар биргән. Казан шәһәренең йөзек кашы булган Иске Татар бистәсендә яшәгән матур татар гаиләләре язмышларын өйрәнү дә күркәм гамәл булыр. Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган шәхесләр белән очрашулар үткәрергә тырышырбыз. Киләчәктә, клуб ныгып киткәч, башка милләт вәкилләре оешмалары белән дә очрашуларны җәйга салырга уйлыйбыз. Ә бүген очрашуга Мәрҗани мәчетендә Татарстан Республикасының халык артисты Гөлзада Сафиуллина җитәкчелек иткән «Мөнәҗәтләр» ансамблен чакырдык.

Без сөйләшкән арада, кунаклар әдәби салонда үз урыннарын алганнар инде инде. Милли киемнәр кигән калфаклы ханымнар, мәһабәт ирләр халык җырларын, мөнәҗәтләрне күңелгә кереплек итеп башкардылар. Ханым-туташларның йөзләрендә нур балкый, сүзләре мәгънәле. Мондый болгавыр заманда күңелне җылыта торган оешма икән бу.

Рәис МИҢНУЛЛИН. Казан

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, матбугат ветераны **Гаҗилә Сәетгәрәй кызы КӘРИМУЛЛИНА** бу көннәрдә 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Киң күңелле, һәрвакыт ярдәмчел ветеранybыз «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасына эшкә туган төбәге – Кама Тамагы район газетасында хезмәт чыныгуы алганнан соң килә. Казан дәүләт педагогия институтында югары белем ала, «Социалистик Татарстан»да корректор, хәбәрче, озак еллар дәвамында җаваплы секретарь урынбасары вазыйфаларында була, хезмәтен җиренә җиткереп башкаруы белән ихтирам яулый.

Туганнары, якташлары, редакция коллективы белән дә ул гомер-гомергә дустанә мөнәсәбәттә. Бу яктан да һәрберебезгә үрнәк.

Киләчәктә дә бәхетле гомер, тазалыкта-саулыкта яшәүләр насыйп булсын!

«Ватаным Татарстан» газетасы коллективы

Тормыш кыйпылчыклары

Бүләк

Бәйрәмнәр, туган көннәр җиткәч, бүләк сайлау катлаулы бер эшкә әйләнеп китте хәзер. Нигә дисәң, кемне нәрсә белән шаккатыра аласың инде? Кибетләрдә бар нәрсә дә тулып ята. Һәркем үзе ошатканын, үзенә кирәген сайлап ала.

Үземнең дә күргәнем бар. Күп кешенең өендә хәзер «бүләк тартмасы» дигән урын бар. Үзләренә кирәк булмаган, әмма ыргытырга да кул бармаган яңа әйберләр саклана анда. Начар әйберләр дә түгел инде алар. Әмма сиңа кирәкмәгәч, башкаларга да кирәкми бит инде ул. Акча мәсьәләсе дә бик бәхәсле. Аз булса, саран дип уйлаулары бар. Күп бирергә һәркемнең дә кулыннан килми. Мин монда юбилейлар, туйлар турында сүз алып бармыйм инде. Аларында ниндидер бер стандарт бар әле. Чыгымнарны капларга дип, бик җайлы гына урнаша алары.

Бүләк турында яза башлавым юктан гына түгел, кинәт кенә бер вакыйга искә төшкәннән иде.

Бервакыт шулай күршедә яшәүче танышыма гаиләсе белән улы кунакка кайтып төште. Күптән күренгәннәре юк иде. Аралар да ерак, мөнәсәбәтләр дә бераз сүнгән иде, ахры. Танышым бик шатланды. Оныкларын да юньләп күргәне юк иде бит. Төн йокламый пешеренде, сыйлады. Балаларга да бик ошап китте. Бер айга дигәннәр иде, еллары дүрт айга сузылды. Шул вакыт эчендә күршемнең түгәрәк юбилее да килеп җитте. Бәйрәм табынына безне дә чакырдылар. Шунда улы белән килене әниләренә иске смартфон бүләк иттеләр. Үзләренә яңаны алганнар икән. «Эшли әле ул. Пыяласы ватык та, кнопкалары гына азрак сафтан чыккан», – дип, аңлатма да биреп куйдылар. Табын янында ниндидер уңайсыз тынлык урнашты. Хәтта күршем дә бу хәлтне бозарга көч тапмады: сүзсез калды. Шул вакыт нәрсәнеңдер, каты итеп шалтырап, плитәгә килеп төшкәне ишетелде. Ни булды икән дип йөгереп чыксак, улының яңа смартфоны идәндә чәчелеп ята. Оныклар алганнар да: «Миңа бир дә миңа бир», – дип, тарткалаша торгач, төшереп җибәргәннәр икән. Үзе әкият кебек бу вакыйга, әмма, ни кызганыч, чынбарлык иде.

Шушы хәлгә ияреп, тагын берсе искә төште. Бала туу хөрмәтенә иптәш кызыма ире алтын сәгать алып биргән иде. Бу гамәлен әнисе бик ошатып бетермәгән. «Мин сине табып үстердем, укыттым, өйләндердем. Миңа шундый зур бүләк алу турында уйлап та караганың юк әле», – дип, килене алдында улына дәгъва да белдергән. «Син барыбер өйдә генә утырасың, иртәгә кунакка барасым бар», – дип, тагып ук киткән. Һәм... төшереп калдырган. «Суга төшкән кебек юк булды», – дип елый-елый антлар эчте дигәннәр иде. Ышандылар инде ышануын. Була торган хәл бит. Әмма арада барыбер ниндидер бер пәрдә калды кебек. Бүләк дигәннәре ниндидер бер илаһи көчкә ия бугай ул. Димәк, бирсәң, кешене сөендерерлек, күңелгә рәхәтлек өсти торган булсын. Хәлеңнән килмәсә, бәлки, бирмәскәдер дә, икенче очрактагы кебек, кеше өлешенә дә кермәскәдер.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАЗАНДА ТУГАН МОГҖИЗА

Узган атна азагында спорт тарихында һәм дөньяда тәүге мәртәбә оештырылган «Киләчәк уеннары»на матур нокта куелды. Дөресрәге, Казандагысына. Оештыручылар Уеннарга якты киләчәк юрады. Башкаладагысы һәм беренчесе ничек истә калды?

tatarstan.ru

Җиңүчеләр

Фиджитал-футбол – Penarol (Уругвай)
Фиджитал-узыш – SMP Racing (Россия)
MLBB турниры – AP.Bren (Филиппин)
Дроннар ярышы – Team Mins Korea (Көньяк Корея)
Фиджитал-баскетбол – Liga Pro Team (Россия)
CS 2+лазертаг – XGod Dosia&mou (Казахстан)
Роботлар ярышы – DS Robotics (Һиндстан)
Dota 2 – Xtreme Gaming (Кытай)
Фиджитал-хоккей – Liga Pro Team (Россия)
Фиджитал-скейтборд – Latino Gang (Аргентина)
Standoff 2 + лазертаг – Absolute (Россия)
«Танклар дөньясы» – Beyond (Россия)
Warface + лазертаг – Young (Россия)
Фиджитал-көрәш – Kuznya (Россия)
Кибатлетика – Russian Cyborgs (Россия)
Виртуаль велоузыш – MInsk (Белоруссия)

Волонтерлар ни уйлый?

Дмитрий КУТЯВИН, Хакасия Республикасы, Абаза шәһәреннән волонтер:
– Казанда тәүге тапкыр. Икенче югары белем алырга теләсәм, бәлки, Казанны сайлармын. Фиджитал-футбол юнәлешендә тим-лидер идем. «Казан Экспо»да юл күрсәтеп торучы булдым. Фиджитал-спорт турында беренче тапкыр «Киләчәк уеннары» хакында белгәч ишеттем. Волонтерлар штабында безнең өчен танылган спортчылар белән очрашулар оештырылды, хәтта берничә сорау да бирдем. Кумирың белән очрашу бәхете һәркемгә дә тәтеми бит ул!

Сәвия ШАКИРҖАНОВА, «Киләчәк уеннары»ның иң өлкән волонтеры:
– Әтнә районының Олы Бәрәзә авылында тудым. Миңа – 83 яшь. Волонтер булып 2017 елдан бирле эшлим. Без инде – «көмеш» волонтерлар. Шундыйлар белән аралашып, киңәшләшеп яшибез, шөкер. Балаларым – бер гаилә, бусы – икенче гаиләм. «Киләчәк уеннары»нда «Хезмәт резервлары» объектында штаб волонтеры идем. Эш урыным – компьютер каршында. Яшь волонтерлар миңа оныкларым кебек. Яшьләр хәзер бик акыллы, бик әдәпле, бөтенесен беләләр, тиз отып алалар, алар белән теләсә нинди темага сөйләшеп була. Киләчәк менә шушындый яшьләр кулында, шөкер. Башкалабыз өчен шулкадәр шатланам. Нинди зур хезмәт бит бу! Мондый зур чаралар 2013 елда Универсиададан башланды. Менә шунда татарның кунакчыл икәнен белеп алдылар инде!

Алга, киләчәккә!

Без булдырдык! Уеннарның ябылу тантанасына килгән җитәкчелек, оештыручылар, сөенеп, ярышларның тәмамлануын әнә шул сүз белән аңлатты. Хәер, чарада сүзләр артык иде. Казан өчен дә, гомумән, ил өчен дә тансык ярышлар халыкка кабат бәйрәм рухын алып килде. Ике атна дәвамында шул рух белән яшәлде, командалар өчен җан атылды, җиңү шатлыклары да, җиңелү күз яшьләре дә булды.

Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко Казандагы турнирның зур уңыш белән үтүен белдерде.

– Дуслар, без моны булдырдык! Тарихта беренче Уеннар узды! Россия фиджитал дип аталган форматта спортның яңа төрләрен берләштергән турнир уйлап тапты һәм үткәрде! – диде ул ябылу тантанасында. – «Киләчәк уеннары» дөньяда танылды, бренд булды. Һәм бу – бик зур уңыш. Әлбәттә, кунакчыл Казанга һәм Татарстанга зур рәхмәт.

Вице-премьер әйтүенчә, Казан бу турнир белән хушлаша, әмма «Киләчәк уеннары» өчен барысы да әле башлана гына. «Без эстафетаны башка илләргә тапшырабыз. Алга, киләчәккә!» – диде Мәскәү кунагы. Тик киләсе Уеннарны кайсы ил кабул итеп алачагы билгесез калды.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исә Казанның тагын бер тапкыр бөтен дөньяга ярышларны ничек оста итеп, югары дәрәҗәдә оештырып булуын күрсәтте.

– Ике атна дәвамында Казан дөньяның игътибар үзәгендә булды. «Киләчәк уеннары» бик күп кызыклы яңалыклар ачты, күпләр аның нәрсә икәнен белде. Ышанычы, шулай ук турнир ачылышына вакыт табып килүе өчен Президент Владимир Путинга, ачылышта катнашкан башка дәүләт башлыкларына да рәхмәт белдерәсем килә! – диде ул.

Ачылыш тантанасыннан аермалы буларак, ябылуны күбрәк концерт дип атарга буладыр (оештыручылар сүзе белән әйтсәк, фиджитал-дискәтүк). Шулай инде: эшләп арыгач, ял да итә бел! Шулай итеп, чыннары белән бергә сәхнәгә виртуаль артистлар да чыкты. Чебурашкадан дөнья йолдызы ясадылар, турнир ачылышында «йоклап» калган робот-этне дә «уяттылар» бу юлы.

> **Владимир ПУТИН, Россия Президенты:**
> Без һәрвакыт спортны һәм аның югары гуманистик кыйммәтләрен алга сөрү яклы булдык. «Киләчәк уеннары» – дөньякүләм спорт гаиләсенә бездән бүләк!

Үпкәле туп

Уен кырына кулларына телефон тотып чыккан футболчылар, ике кызыл карточка һәм Гама тәхәллүсле спортчының үпкәсе. Фиджитал-футбол буенча турнир «Киләчәк уеннары» ябылу тантанасы алдыннан гына тәмамланды. Беренче урын өчен уен шулкадәр киеренке узды ки, кайберәүләрнең кан басымы 220гә кадәр җитте.

Фиджитал-футбол буенча ярышта 16 команда көч сынашты. Казанга Парагвай, Чили, Мексика, Камерун кебек илләрдән дә килделәр. Көндәшләр башта компьютер уенында мөмкин кадәр күбрәк гол кертергә тырыша, аннары чын кырга чыга. Футбол кыры гадәттәгедән кечкенәрәк булса да, капкалары шундый ук зурлыкта. Оештыручылар моның серен дә чиште: бу – туп кертү җиңелрәк булсын өчен махсус эшләнгән. Ни дисәң дә, фиджитал-футбол ул – тамаша. Ә беренче урын өчен көч сынашкан Россия һәм Уругвай командалары чын тамаша күрсәтте. Көндәшләр, уен башланганчы ук, аздан гына бер-берсенең якасына ябышмады. Социаль челтәрләргә куярга кызыклы видеолар төшерергә дип, футбол кырына кулларына телефон күтәреп чыккан уенчылар моны махсус эшли кебек тә тоелды хәтта. Дөрес, уйнаулары чын иде. Махсус экранда аларның йөрәк тибешенә кадәр күрсәтеп тордылар: бер уенчының кан басымы 220гә күтәрелде.

Хөкемдарларга да эш күп булды. Өчәр минутлык ике тайм барышында уен кырының әле бер башында, әле икенчесендә җәнҗал купты. Россия хөкемдарлары инглиз телен белсә дә, Уругвай уенчылары белән уртак тел таба алмадылар. Шуңа күрә үзара аңлашу өчен кулдагы бармакларга кадәр эшкә җиктеләр. Тупас уен һәм дорфалык өчен «Локомотив»ның ике уенчысына кызыл карточка күрсәттеләр. Мондый очракта кырга башка уенчылар чыга.

Җәза алучыларның берсе – «Локомотив» уенчысы Гамид Шахбанов (тәхәллүсе – Гама) – хәлиткеч уенның бер өлешен җанатарлар белән бергә карады. «Үз илебездә уйныйбыз бит. Ник бу кадәр катгый кыланырга?» – дип, хөкемдарларга карата фикерен белдерде ул. «Локомотив»ның җиңелеп баруы да кәефен тәмам кырды. Янәшәсенә автограф алырга дип килгән балаларга бер генә әйтте, шуннан соң күпме утырса да, янына беркем килмәде. «Локомотив» финал уенында 5:6 исәбе белән оттырды. Ә Уругвай командасына акчалата приз белән бергә түбәтәйләр дә бүләк иттеләр. «Килгән шәпкә бик салкын иде. Хәзер исә бар да шәп. Казан безне җылы кабул итте. «Киләчәк уеннары» кабат Россиядә узса, без һичшиксез киләчәкбез», – дип, хисләре белән уртаклашты Уругвай командасы капитаны Хорхе Марсело Родригес Нуньес.

Илләр йөзе – кызлар

«Киләчәк уеннары» ачылышында булган Илләр парады әлеге тантананың иң истә калган мизгелләренең берсе булгандыр. «ВТ» хәбәрчесе шунда катнашкан кызлар белән аралашты.

Махриджемал ХОДЖАНЯЗОВА (Төрекмәнстанны тәкъдим итте):
– Ачылышка озак әзерләндек. Репетиция вакытында оештыручылар безгә карата кырыс та, таләпчән дә булды. Гади генә нәрсә кебек, ләкин бик борчылдык. Зур чара бит! Үз илемне тәкъдим итүем белән бик горурланам. «Төрекмәнстан» дигән мизгелдә йөрәгем чыгып китәрдәй булды. Йөзем шатлыктан балкып торды. Бу – минем өчен зур дәрәҗә. Киберспорт уеннары шулкадәр популяр дип уйламаган идем.

Екатерина МОРОЗОВА (Россияне тәкъдим итте):
– Республикабызның төрле почмакларыннан 110 модель көн саен диярлек дөньякүләм чараның ачылышына әзерләнде. Бу көн мәңгегә тарихка кереп калачак. Кызлар белән бердәм команда идек, нәтиҗә матур булсын өчен эшләдек. Һәр адым, күз карашы, кул хәрәкәте мөһим иде. Сәхнәгә чыкканда һәм илебезне игълан иткәндә тамашачыларның эмоцияләрен күреп, әйтеп бетерә алмаслык хисләр кичердем. Барыбызны да илебез һәм кешеләребез өчен чиксез мәхәббәт һәм горурлык хисе биләп алган иде. Бөтен зал торып басты, кул чапты, елады... Бу хисләрне мин гомерлеккә истә калдырачакмын. Алты ил Президенты алдында чыгыш ясау бит бу!

Уеннар – саннарда



- ✓ Ярышлар **10** көннән артык барды.
- ✓ **294** команда катнашты.
- ✓ Спортчылар **21** юнәлештә көч сынашты.
- ✓ Гомуми приз фонды – **10** млн доллар.
- ✓ Катнашучылар **2** меңнән артык иде.
- ✓ Иң яшь катнашучыга – **12,** иң өлкәненә – **62** яшь.
- ✓ Россия, Кытай, Һиндстан, Казахстан, Белоруссия, Көньяк Корея, Испания, Уругвай, Аргентина, Эквадор, Колумбия, Филиппин илләреннән **236** спортчы тәүге Уеннарның җиңүчесе булып танылды.
- ✓ **300** меңнән артык тамашачы карады.
- ✓ Турнирга бәйле контентны **280** канал күрсәтте.
- ✓ **800** сәгать туры эфир оештырылды, караулар **2** миллиардтан артып китте.
- ✓ Уеннарга Россия төбәкләреннән – **820,** Казаннан – **967,** Татарстан районнарыннан – **75** волонтер, **22** илдән **41** чит ил волонтеры җәлеп ителгән иде.

Эльвира ВӘЛИЕВА, Чулпан ГАРИФУЛЛИНА, Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 225

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+